وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! *(Коръән, 3:103)*

6+

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№6 (239). ИЮНЬ - 2015 / ШАГБАН - РАМАЗАН - 1436

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ

## ТАТАРСТАН МӨФТИЕ КАМИЛ ХӘЗРӘТ СӘМИГУЛЛИННЫҢ РАМАЗАН АЕ БАШЛАНУ УҢАЕННАН КОТЛАВЫ



Әссәләәму галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ! Мөхтәрәм дин кардәшләребез!

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән Изге рамазан ае башлану белән ихластан котлыйм!

Мөхтәрәм җәмәгать, барчабызга мәгълүм, исламның биш баганасы бар. Биш багана ул - Аллаһка һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә шаһитлык китерү, намаз уку, зәкят бирү, хаҗ кылу һәм ураза тоту. Рамазан аенда менә шушы биш багананың берсен үтәргә, ягъни ураза тотарга мөмкинлек бирелгән. Коръәндә әйтелгән: "Ий, иман китергән бәндәләр, сездән алда килеп-киткәннәргә фарыз ителгән кебек, ураза тоту сезгә дә фарыз кылынды. Бәлки, сез шаять тәкъва булырсыз?" ("Бәкара" сүрәсе, 183 нче аять).

Пәйгамбәребез саллэллаһу гәләйһи вә сәлләм хәдисендә язылган. "Аллаһ: "Адәм улының эшләгән һәр хәерле эше үзе өчен һәм ул уннан алып җитмеш тапкырга кадәр артыр. Ураза бары тик минем өчен генә. Аның савабын да мин бирермен", - дип әмер итте". Без рамазан дәвамында уразалар тотып, гөнаһларыбызны кичерүне сорап догалар кылабыз. Рамазан аенда иман белән һәм савапка ирешүгә өмет баглап, ураза тоткан кешенең элеккеге барча гөнаһлары да ярлыканыр, иншә Аллаһ. Раббыбыз догаларыбызны кабуллардан кылса иде!

Рамазан безне мәрхәмәтле, игелекле булырга өйрәтә, күңелләребезне тәрбияли. Сөекле Пәйгамбәребез саллэллаһү гәләйһи вә сәлләм кисәтә: "Кем рамазанда алдауны һәм ялган шаһитлык итүне дәвам итә - юкка ризыктан һәм судан тыелып тора". Рамазан ул - начар гамәлләрдән котылу, холкыбызны яхшырту һәм авыр гөнаһлардан арыну өчен мөмкинлек. Тагын бер хәдис шул хакта ачык аңлатып бирә: "Ашау-эчүдән тыелу гына ураза тоту түгел. Бәлки яман сүздән, әшәке нәфестән тыелу - чын ураза. Әгәр бер кеше сине сүксә, син әйт: "Мин - руза", -диген". Хәтта яман сүз әйтсәләр дә, яман сүз белән җавап кайтарма.

Быел безнең җирлектә яшәүчеләргә уразаны 20 сәгатьтән артык тотарга туры килә. Хәдисләрдән мәгълүм булганча, фәрештәләр ураза тотучыларның гөнаһларын кичерүне сорап догалар кыла. Аллаһы боерса, безнең ураза тотучы мөселманнарга догалар күбрәк тә ирешер, алар бит дөньяның башка җирләрендә яшәүчеләргә караганда уразаны озаграк тота. Монда да Раббыбызның бер хикмәте бар.

Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгалә токкан уразаларыбызны, кылган гамәл-гыйбадәтләребезне кабул итсен, үзенең рәхимшәфкатеннән ташламасын иде. Аллаһ исемен зикер итеп, күңелләребез белән бары Коръәнгә, иманга ашкынып үткән рамазан ае савапларын күрергә язсын. Рамазан ае мөбарәк булсын!



**8-10 бит**

## Болгар җире илебез мөселманнарын берләштереп торачак



**11 бит**

## Ифтар ашлары кайларда уздырыла

"ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ" газетасын өйгә дә яздырып алырга була. Почта бүлекчәләренә мөрәҗәгать итегез.

Индекс – 16046




## УРАЗАГА КЕРӘБЕЗ

**Голәмалар шурасы утырышында хәзрәтләр рамазан ае башлану һәм тәмамлану вакытына, тәравих намазында укыла торган рәкәгатьләр санына, фидия һәм фитыр сәдакаларына кагылышлы дини сорауларны тикшереп, үзара киңәшләшкәч, түбәндәге карарга килделәр:**

рамазанның беренче көне - **18 ИЮНЬ**; беренче тәравих намазы республика мәчетләрендә **17 ИЮНЬДӘ** укыла;

рамазанның соңгы көне - **16 ИЮЛЬ**, ә **17 ИЮЛЬДӘ** - Ураза бәйрәменең беренче көне.

Хәзрәтләр бертавыштан Татарстан мәчетләрендәге имамнар тәравих намазында 20 рәкәгать укырга тиеш дигән фикергә килделәр.

Фитыр сәдакасы күләмен арпа һәм йөзем бәясеннән чыгып билгеләргә килешенде: ул арпа бәясенә карап - **100 сум,** йөзем бәясенә карап - **500 сум.**

Фидия сәдакасы - **200 сум.**

Нисаб көмеш (**592 грамм**) бәясеннән чыгып исәпләгәндә - **18000.**

Зәкят нисабы алтын **(85 грамм)** бәясеннән чыгып исәпләгәндә - **170000 сум.**

## Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН:

# "ТЫНЫЧЛЫКНЫ ГЫЙЛЕМ ЯРДӘМЕНДӘ ҺӘМ ТРАДИЦИОН ДИНГӘ ТАЯНЫП КЫНА САКЛАРГА МӨМКИН"



**"Үткәндә һәм бүгенге заманда Изге Коръәнне тәфсир итү: Изге Коръән һәм сөннәт чагылышында радикализм һәм террорчылыкны профилактикалау" дип исемләнгән I Халыкара ислам конференциясе эшендә ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре буенча департаменты Дини оешмалар белән багланышлар идарәсе башлыгы Илнур Гатауллин, Мәскәү һәм илнең Үзәк төбәге мөселманнары Диния нәзарәтенең эшләр белән идарә итүчесе Марат Сәлахов, шулай ук дини белем бирү йортлары ректорлары, Төркия, Гыйрак һәм Ливаннан килгән ислам дине белгечләре катнашты. Чараның модераторы ролендә ТРның Коръәнне һәм сөннәтне өйрәнү үзәге директоры Фәрид хәзрәт Сәлмән чыгыш ясады.**

Конференция ТРның Коръәнне һәм сөннәтне өйрәнү үзәге тарафыннан ТР мөселманнары Диния нәзарәте ярдәме белән оештырыла. Аның төп максаты - Коръәнгә һәм пәйгамбәрлек традициясендәге хакыйкатькә таянып, радикализмны һәм террорчылыкны профилактикалау буенча гамәли киңәш-тәкъдимнәр булдыру.

Илнур Гатауллин конференциядә катнашучыларга ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәровның сәламләү хатын укыды. Хатта билгеләп узылганча, бүген традицион исламда барлыкка килүче экстремистик агымнар, мөселманнар арасында ызгыш-талаш таратып кына калмыйча, башка дин вәкилләренә карата да нәфрәт уята. "Әлеге явызлык бүген бөтен дөньяда хөкем сөрә һәм кешелеккә яный. Аны корал кулланып түгел, сүз белән җиңәргә кирәк. Бу эштә мөфтиләр һәм шәехләрнең, имамнар һәм дини белем бирү йортлары җитәкчеләренең, теологлар һәм дин галимнәренең роле зур. Радикализмга һәм террорчылыкка каршы көрәштә дин әһелләренең, дәүләт органнарының, хокук сакчыларының, җәмәгать эшлеклеләренең, фән һәм мәдәният вәкилләренең һәм, гомумән, барлык кешеләрнең көчен берләштерү зарур. Татарстанда бу юнәлештә зур эш башкарыла. Республика тәҗрибәсе конференциядә катнашучыларга файдага булыр", - диелә сәламләү текстында.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үзенең чыгышында, Коръәннең мөселманнарны бары тик игелекле, намуслы, гадел һәм мәрхәмәтле булырга өйрәтүен искәртте. "Изге китапта экстремистлыкка һәм террорчылыкка чакырулар юк, бу мөмкин дә түгел, чөнки ислам сүзе үзе үк сәлам, ягъни тынычлык дигән сүздән килеп чыккан. Бары тик наданнар, рухи тәрбия алмаганнар гына исламга һәм кешелеккә каршы коточкыч җинаятьләр кылуга сәләтле... Бүген җәмгыятьтә тынычлыкны белем бирү ярдәмендә һәм традицион дингә таянып кына сакларга мөмкин", - диде ул.

Камил хәзрәт тагын бер актуаль мәсьәләгә игътибар юнәлтте: бүген Коръәннең рус теленә дөрес тәрҗемәсе юк. Ул булган тәрҗемәләрдә ялгышларның һәм төгәлсезлекләрнең күп булуын ассызыклады. Мөфти билгеләп узганча, ТР мөселманнары Диния нәзарәте 4 ел элек бу юнәлештә эш башлаган инде һәм тиздән Коръәннең тәрҗемәсе дөнья күрәчәк.

ТР мөфтие Коръәнне тәфсир кылу мәсьәләләренә тукталып, гарәп телеп, шәригать кануннарын, ислам гыйлемен камил белми торып, бу эшкә керешмәскә кирәклеген ассызыклады.

## Михаил БАБИЧ:

# "КӨНДӘШЛЕККӘ СӘЛӘТЛЕ БЕЛЕМ ҮЗӘКЛӘРЕН ҮЗЕБЕЗДӘ БУЛДЫРЫРГА КИРӘК"

**Россия Федерациясе Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле Михаил Бабич Оренбургта диния нәзарәтләре рәисләре белән очрашты. Очрашуда Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин үзенең урынбасары Рәфыйк Мөхәммәтшин белән бергә катнашты.**

Дин әһелләре Президент вәкиле белән башлыча дини мәгариф хакында сөйләштеләр. Михаил Бабич мондый төр очрашуларның даими уздырылуын һәм дин өлкәсенә кагылышлы проблемалар, проектлар хакында сөйләшүнең кирәклеген билгеләп узды. "Эшебезнең нәтиҗәсе бар. Без бергәләп ислам мәгарифе системасы нигезен салдык. Казанда һәм Уфада югары белем бирүче дини уку йортлары базасында имамнарның квалификациясен күтәрү курсларын оештырдык. Соңгы ике елда әлеге курсларда меңнән артык дин әһеле белемен күтәрде. Әлеге курслар традицион ислам белемнәрен туплау мәйданчыгына әверелде", - диде М. Бабич.

Шулай ук ул өч баскычлы дини мәгариф системасын булдыру мөһимлеген ассызыклады. "Дәүләт җитәкчесе тарафыннан Россия төбәкләрендә көндәшлеккә ия дини белем алу өчен барлык шартлар тудыру бурычы куелды. Яшьләр дини белем алыр өчен чит илләргә китә. Көндәшлеккә сәләтле белем үзәкләрен үзебездә булдырырга кирәк", - диде ул. Шушы бурычны тормышка ашыру максатыннан "2014-2016 елларга ислам мәгарифе программасы" кабул ителде һәм 800 млн сум күләмендә акча бүлеп бирелде.

Татарстан мөфтие игътибарны мәгълүмати технологияләрне куллану мөһимлегенә юнәлтте. Бу бигрәк тә идеология һәм мәгариф системасына кагыла. Моннан тыш дини белем бирү сыйфатын үстерү әһәмиятенә басым ясады. Россия ислам мәгарифе дәрәҗәсен күтәрү, мөселман галимнәрен, дин белгечләрен бер урынга туплау ниятеннән Ислам академиясен булдырырга тәкъдим итте.

- Болгар ислам академиясе проектын Россия Президенты Владимир Путин һәм Татарстан Президенты вазыйфаларын башкаручы Рөстәм Миңнеханов хуплады. Академия кысаларында Болгар Голәмалар шурасы, фәнни-уку-укыту үзәге, ислам китапханәсе, эксперт советы, татар дини-рухи мирасын өйрәнү үзәге эшләячәк. Алга таба академия базасында аспирантура, докторантура, мөселман каллиграфиясе мәктәбен оештыру яхшы булыр иде ,- диде ул.

Татарстан мөфтие Россия мөселман галимнәре берлеген булдырырга тәкъдим итте. Ислам социаль доктринасы хакында фикерләрен дә җиткерде.

Россиядә яшәүче мөселманнарның ихтыяҗларын кайгыртуда һәм динара, милләтара татулык саклауда, дини-рухи мирасыбызны өйрәнүдә һәм баетуда академиянең дә, доктринаның да роле зур булачагына басым ясады.

***



**Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җиденче мәртәбә уздырылучы Россиякүләм авыл Сабантуенда катнашты. Быел әлеге Сабантуй Оренбург өлкәсенең Татар Каргалысы авылында узды. Бәйрәмгә Татарстан Президенты вазыйфаларын башкаручы Рөстәм Миңнеханов, Оренбург гебернаторы Юрий Берг һәм башка рәсми затлар да килгән иде.**

# МӨФТИ "KAZANSUMMIT-2015" VII ХАЛЫКАРА ИКЪТИСАД САММИТЫНДА КАТНАШТЫ

**Татарстан башкаласында Россия һәм Ислам хезмәттәшлегe оешмасы илләренең "KazanSummit-2015" VII Халыкара икътисад саммиты узды. Бисмилла әйтеп һәм Татарстан Президенты вазыйфаларын башкаручы Рөстәм Миңнехановның сәламләве белән башланып киткән халыкара чарада мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин да катнашты.**

Быел анда катнашырга теләк белдергән илләр һәм вәкилләр саны узган елгыдан күбрәк булып чыккан: былтыр форумга 25 илдән 500ләп кеше килсә, быелгы чарада Россия, Төрекмәнстан, Таҗикстан, Казакъстан, Латвия, Әзербайҗан, Төркия, Согуд Гарәбстаны, Мисыр, Пакьстан, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Сомали, Иран, Малайзия, Бөекбритания, Люксембург, Италия, Марокко, Палестина, Маврикий, Катар, Нидерланд, Нигерия, Бруней-Даруссалам һ.б. - барысы 45 илдән 746 вәкил катнашырга теләк белдереп теркәлгән. Шушы халыкара чарада катнашучылар арасында илебез һәм чит илләр финанс оешмалары вәкилләре, дәүләт корпорацияләре һәм эре бизнес җитәкчеләре, дәүләт эшлеклеләре бар.

"Әлеге форум бездә 7 нче тапкыр уздырыла һәм ул Россия Федерациясе һәм аның төбәкләренең ислам дөньясы белән хезмәттәшлеккә юнәлдерелгән. Бу безнең зур илебезнең икътисади һәм инвестицион мөмкинлекләрен Татарстан мисалында күрсәтү өчен зур ярдәм", - дип сүзен башлады ТР Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов. - Хәзерге вакытта ислам икътисады ул икътисад, сәүдә үсешенең, инвестицияләр алуның һәм ислам дөньясы белән хезмәттәшлек итүнең иң отышлы коралы", - дип, ул Татарстанда исламча икътисад белән шөгыльләнүче оешмаларны мисалга китерде. Шулай ук җәмгыятькә тиешле дәрәҗәдә мәгълүмат бирү һәм бу өлкәдә белгечләр әзерләүче югары уку йортлары хакында да искәртте.

"Без сезнең белемегезгә һәм тәҗрибәгезгә мохтаҗ. "KazanSummit-2015" Россия Федерациясенә Ислам дөньясы белән сәүдә-сәнәгать һәм инвестицияләр, банк өлкәсендә хезмәттәшлекне ныгытуга ярдәм итәр дип ышанып калам", - диде Рөстәм Миңнеханов һәм "KazanSummit-2015"ка килүчеләргә рәхмәт әйтте.

# КУРСАВИ МИРАСЫ ХАЛЫККА КАЙТАЧАК

**Казанда күренекле ислам дине тәгълиматчысы, татар мәгърифәтчесе Габденнасыйр Курсавиның тууына 240 ел тулуга багышланган республикакүләм фәнни конференция узды. Конференциядә Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батров, ТР мәдәният министры урынбасары Гүзәл Нигъмәтуллина, Арча районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Илнур Котдусов, галимнәр Марсель Әхмәтҗанов, Рафаил Шәйдуллин, Айдар Хабетдинов, Альфрид Бустанов, Рәшит Галләм, Рамил Әдһәмов, Саид-Дамир Шаһавиев, Резеда Сафиуллина, Нияз Сабиров, Данияр Гыйльметдинов, Урта Курса авылы мәчетенең имам-хатыйбы Вәдүт хәзрәт Вафин катнашты.**

Габденнасыйр Курсави (Әбүннасыйр Габденнасыйр бине Ибраһим бине Ярмөхәммәд бине Иштирәк әл-Курсави) 1776 елда хәзерге Арча районы Курса авылында сәүдәгәр гаиләсендә дөньяга килгән, үзеннән соң бөтен ислам дөньясына бәһасез мирас калдырган татар галиме. Югары Курса авылында Курсави үзе имам булып хезмәт иткән тарихи мәчет бүгенге көнгәчә сакланган.

Форумда мөселман дини тәгълиматында Габденнасыйр Курсавиның тоткан урыны, аның ислам яңарышына һәм татар иҗтимагый фикеренә керткән өлеше, Россия мөселман өммәтенең камилләшүенә алдынгы фикерләренең йогынтысы, дин һәм мәгариф өлкәсендәге эшчәнлеге һ.б. сораулар каралды. Габденнасыйр Курсавиның иҗади мирасын тарату һәм 2016 елда аның тууына 240 ел тулу уңаеннан үткәреләчәк чаралар турында аерым фикер алышулар да булды. Конференциядә катнашучылар төрки-мөселман дини мәктәбенең күренекле вәкиле булган Габденнасыйр Курсавиның дини һәм иҗтимагый-фәлсәфи хезмәтләрен халыкка танытыр өчен булдыра алганча көч куярга кирәк, дигән бердәм фикергә килделәр. Габденнасыйр Курсави мирасын популярлаштыру максатыннан ул укыткан Югары Курса авылы мәдрәсәсе бинасын торгызуны; Югары Курса авылында "Курсави укуларын" үткәрүне; Татар иҗтимагый фикерен һәм мөселман дини тәгълиматын өйрәнүче галимнәр өчен Габденнасыйр Курсави исемендәге премияне булдыруны; Курса авылы мәктәбенә Г. Курсави исемен бирү тәкъдимен хуплауларын, финанс ярдәме күрсәтүләрен сорап, Татарстан Республикасы җитәкчеләренә мөрәҗәгать итәргә карар кылдылар.

# НӘЗАРӘТТӘ ИСКЕ ТАТАР ИМЛЯСЫ ХАКЫНДА СӨЙЛӘШТЕЛӘР



**ТР МДН бинасында Татар дин галимнәре елы уңаеннан чираттагы чара булып узды - иске имляга багышланган түгәрәк өстәл оештырылды. Аерым алганда, сүз иске имляда уртак кагыйдәләр булдыру турында барды. Әлеге чарада ТР МДН рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстанның элекке мөфтие Илдус хәзрәт Фәйзов, баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев, филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов, Голәмалар шурасы әгъзалары, галимнәр, мөгаллимнәр катнашты.**

Сөйләшү барышында катнашучылар иске татар телендә укый белерлек шәкертләр әзерләү, алар өчен кирәкле уку-укыту методикасын камилләштерүнең әһәмияте һәм бу эшне эзлекле рәвештә алып барырга кирәклеге турында белдерделәр. Марсель Әхмәтҗанов фикеренчә, укучыларны гади программалар белән җәлеп итәргә һәм бу эштә электән килгән хезмәтләргә таянырга кирәк. Иске имляда махсус сүзлек булдыру да бу юнәлештә алга китәргә этәргеч булыр иде. Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты вәкилләре дә, Диния нәзарәтенең башлангычына теләктәшлек белдереп, бу өлкәне тирәнтен өйрәнүдә фәнни кадрлар белән тәэмин итә алулары турында әйттеләр.

Халыкта иске имляны өйрәнүгә ихтыяҗ тудыру, татар дин галимнәренең хезмәтләрен күпләп бастыру, ТР МДН мәгълүмати-белем ресурслары аша иске имля буенча дәресләр биреп бару һәм уртак грамматик кагыйдәләрне туплаган китап булдыру мәсьәләләре шулай ук үзәктә торды. Түгәрәк өстәл ахырында махсус эшче төркем төзелде. Алар иске имляның барлык кагыйдәләрен тәртипкә салып, бердәм стандарт булдыру белән шөгыльләнәчәк. Эшче төркем беренче нәтиҗәләрен бер айдан соң тәкъдим итәр дип көтелә.

# КАМИЛ ХӘЗРӘТ – КОРЪӘННЕ ТАПШЫРУЧЫ ГАЛИМНӘР ЧЫЛБЫРЫН ДӘВАМ ИТҮЧЕ

**Татарстан мөфтие, мөхтәрәм дин әһеле Камил хәзрәт Сәмигуллин изге Коръән буенча иҗазәт алды. Иҗазәт ул - Коръәнне тулысынча ятлау, дөрес уку һәм аны башкаларга өйрәтә алу хакындагы документ. Бу документ мөфти Камил хәзрәтнең Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләмнән башланган һәм Коръәнне тапшыручы галимнәр аша өзелми килгән чылбырны дәвам итүче дин әһеле икәнен раслый.**

Республикабыз мөселманнары, дин әһелләре җитәкчесенең бөтен ислам дөньясында зур дәрәҗәгә, мәртәбәгә ирешкән хәзрәт булуы – бар Татарстан өммәте өчен шатлык һәм горурлык.

Иҗазәт "бисмилла" сүзе белән башланып китә. Документта гыйлем алуның, ислам фәннәрен таратуның һәм гыйлемне чылбыр буенча – остаздан укучыга тапшыра килүнең мөһимлеге әйтелгән. Иҗазәттә остаз һәм аның укучысының исеме, Пәйгамбәрдн башлап чылбырны дәвам итүчеләр күрсәтелгән. Ахырда остазның мөһере һәм имзасы куелган.

Камил хәзрәт Изге Коръәнне дөрес итеп укырга Россия ислам институты мөгаллиме - Мисыр галиме Хәсән Хадидән өйрәнде.

Шуны да әйтергә кирәк, исламның төрле фәннәре буенча иҗазәткә ия дин әһелләре сирәк. Мөфти хәзрәтләренең исә бик күп фәннәр буенча гыйлем тапшырырга хокукы бар. Әйтик, шәригать фәннәре буенча ул чылбырны шәех Мөхәммәд Ризавидан соң дәвам итә. Бу иҗазәт фикыһ, фикыһ ысулы, гакыйдә, хәдис, хәдис ысулы, хөснел хат, сарыф (морфология) һәм нәһү (грамматика) буенча. Ул Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләмнән башлап Әбү Хәнифә аша өзелми килгән чылбыр – иснәд булып тора. Шулай ук мөфти хәзрәтләре азан һәм алты ышанычлы хәдисләр җыентыгын укыту буенча иҗазәткә дә ия.

# БАКЧАСАРАЙ РАЙОНЫ ИМАМЫ – ТАТАРСТАННАН

**Татарстан мөфтие урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин Кырымга эшлекле сәфәре кысаларында Кырым мөфтие Әмирали хаҗи Аблаев белән очрашты.**

Рөстәм хәзрәт Кырым мөселманнары җитәкчесенә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның сәламнәрен җиткерде. Шулай ук нәзарәтнең проектлары, чаралары хакында сөйләде. 14 июньдә узачак Изге Болгар җыенында катнашырга чакырды. Моннан тыш Кырым мөфтиен Бакчасарай районы мәчете имамы белән таныштырды. Җирле мөселман өммәте соравы буенча Бакчасарай районына имам Татарстаннан җибәрелде. Яңа имам Ринат хәзрәт Хаҗиев РИИны тәмамлаган, Төркиядә укыган.



# РОССИЯ ИСЛАМ ИНСТИТУТЫНДА ИСЛАМ ЖУРНАЛИСТЛАРЫН ӘЗЕРЛИЛӘР

**19 июньдә Россия ислам институтында "Ислам журналистикасы" бүлегенә документлар кабул итү башлана. Быел көндезге һәм читтән торып уку бүлекләренә 15 әр бюджет урыны каралган.**

"Ислам журналистикасы" бүлегендә белем бирү Россиянең журналистлар әзерләүче башка вузларындагы кебек алып барыла. Фәлсәфә, культурология, тарих, чит ил әдәбияты һәм башка фәннәр укытыла. Шулай ук журналистика фәннәре: стилистика һәм әдәби редакцияләү, массакүләм мәгълүмат чаралары системасы, журналистика теориясе нигезләре, ммч техникасы һәм технологиясе һәм башкалар укытыла. Моннан тыш ислам журналисты өчен мөһим булган дини гыйлем бирелә. Мәсәлән, студентларга ислам хокукына кереш, хәдисләр, Коръән уку дәресләре керә. РИИда булачак журналистлар ике чит тел - инглиз һәм гарәп телләрен өйрәнә.

**"Ислам журналистикасы" бүлеген тәмамлаучылар түбәндәге һөнәрләрне үзләштерә:**

**- корреспондент,**
**- редактор,**
**- фотокорреспондент,**
**- пресс-секретарь,**
**- спичрайтер,**
**- реклама буенча менеджер,**
**- контент-менеджер,**
**- медиапланер.**

# УРАЗА

Татарстан Республикасы мөфтие
Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН




## Уразаның үзенчәлекләре

Ураза гарәпчә "саум" дип атала. "Саум"ның лексик мәгънәсе "берәр нәрсәдән ерагаю, читләшү, берәр нәрсәгә каршы тору" дигәнне белдерә. Менә, мәсәлән, Аллаһы Тәгалә Мәрьям турында болай дип әйткән: "Мин Аллаһ ризалыгы өчен һичкем белән сөйләшмәскә нәзер әйттем, шуның өчен бу көндә һичкем белән сөйләшмим" ("Мәрьям" сүрәсе, 26 нчы аять).

Уразаның шәригатьтә мәгънәсе ураза тотучы кешеләрнең үзләрен икенче фәҗердән (таң атканнан) алып кояш батканчыга кадәр ашау-эчүдән һәм җенси якынлыктан тыюларын белдерә.

Икенче фәҗер - "имсак" вакыты. Гарәп телендә "имсак" үз-үзеңне тыю дигән мәгънәне белдерә. Имсак вакытында ястү намазының вакыты чыгып, иртәнге намазның вакыты керә. Шушы вакытта сәхәр ашалып бетеп, ураза башлана. Моннан соң ураза тотучы кеше үзен ашаудан да, эчүдән дә, җенси якынлыклардан да тыя.

Кояш баткан вакыт ифтар вакыты була. Бу вакыттан алып ураза тоткан кешеләр өчен тыелган нәрсәләр рөхсәт ителә. Ахшам намазының вакыты да кергән була.

Имсак мофтыйрат (уразаны бозучы) дип аталган нәрсәләрдән нәфесне чынлыкта яки хөкем рәвешендә тыя. Ялгышып яки онытылып китеп берәр ризык алып капкан чакта хөкмән (хөкемле) имсак барлыкка килә һәм ураза бозылмый. Имсакның капма-каршысы - ифтар. Бер дә ураза тотмау да - ифтар, уразадагы кешеләрнең, кояш баткач, авыз ачулары да ифтар була. Ураза тотканда уразаны бозарлык берәр нәрсә эшләү дә ифтар санала. Ифтар кылган кеше дә, уразаны бозган нәрсәләрнең һәркайсы да "мофтыйр" дип атала. Барысы бергә "мофтыйрат" дип исемләнә. Рамазан аен "Шәһри Сыйам" дип әйтәләр, Ураза бәйрәмен, тыелган вакыт тәмамланганга күрә, "Гийд әл-Фитыр" (ураза төгәлләнү бәйрәме) дип атыйлар.

## Уразаның башлануы һәм тәмамлануы турындагы аять һәм аның тәфсире

"...Сәхәр дә ашагыз, эчегез, хәтта таң якынлыгы беленгәнче (төннең кара җепкә охшаган караңгылыгы китеп, иртәнең ак җепкә охшаган яктылыгы таралганчыга кадәр), аннары уразаны, кояш баеганчы тотып, тәмам итегез!" ("Бәкара" сүрәсе, 187 нче аять). Изге аятьтә "таң яктылыгы беленгәнче" дип әйтелгән. Бу очракта сүз, таң ата башлаганчы беленеп, аннары юкка чыга торган җеп шикелле нечкә генә яктылык сызыгы турында бара. Кара җеп белән чагыштыруның максаты - көн яктылыгының кичнең караңгылыгына кадәр сузылуында. Чөнки таң ата башлаган вакытта офыкның буеннан-буена ак җеп сузылган кебек була. Һичшиксез, таң атканда төн караңгылыгының бер өлеше саклана әле. Чөнки таң нуры, ягъни фәҗер садикъның яктылыгы төн караңгылыгы арасыннан ярылып чыга һәм ак җеп белән кара җеп янәшә күренә башлый. Шуңа күрә, көн яктылыгын беренче ачып җибәргән яктылык - ак җеп, төн караңгылыгына барып тоташканы кара җеп дип әйтелгән. Гадийй Ибн Хатим (радыйаллаһу ганһү) бер ак, бер кара җеп алган. Төннең бер өлешендә аларга караган, ләкин бу ике җеп аңа ап-ачык күренмәгән.

Таң вакыты якынайганда: "Йә, Рәсүлуллаһ! Мин ястыгымның астына ике җеп куйган идем (ләкин ике җепнең берсе дә аерымачык күренмәде)", - дигән. Рәсүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вәссәлам) аңа: "Һичшиксез, бу очракта синең ястыгың артык киң икән. Чөнки (бу аятьтә әйтелгәнчә) ак җеп белән кара җеп синең ястыгың арасында калган (озак йоклагансың)", - дигән (Бохари, "Тәфсир", 28; Мөслим, "Сыйам", 33; Әбү Дауд, "Саум", 17; Дарими, "Саум", 7).

Кичен ашау-эчү һәм җенси якынлыкның тыелмавы шәфәкъ кызыллыгына кадәр сузылганга күрә, әлеге аятьтәге хөкемнең төгәлләнгәнлегеге аны раслаучы "хәтта" сүзе белән билгеләнгән. Шуңа күрә фәҗергә кадәр ашарга мөмкин. Мәсәлән, Гайшәнең (радыйаллаһу ганһә) әйткәннәре риваять ителгән: "Биләл кичен азан әйтә торган булган. Рәсүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вәссәлам) әйткән: "Өмме Мәктум углы азан әйткәнчегә кадәр ашагыз һәм эчегез. Чөнки Өмме Мәктум углы фәҗер беленә башлаганчы (имсак вакыты җиткәнче) азан әйтмәс", - дип боерган (Бохари, "Саум", 17). Аятьтәге "ашагыз, эчегез" дигән әмер фәҗер җиткәнчегә кадәр сәхәр ашау мөмкинлегенә ишарәт итә.

Уразаны төн җиткәнчегә кадәр тәмамлауның максаты кояшның бөтенләй батуы вакытына кадәр уразаны төгәлләүдән гыйбарәт. Мәсәлән: Гомәр Ибн әл-Хәттаб (радыйаллаһу ганһү) сөйләп калдырган бер хәдистә Рәсүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вәссәлам) болай дигән: "Төнлә шушы тарафтан (көнчыгыштан) чыгып, көндез шушы тарафка (көнбатышка) юнәлеп, кояш баткан вакытта ураза тоткан кеше уразасын боза (ягъни уразаны бозу вакыты җитә)" (Бохари, "Саум", 43).

Бу хәдистә көннең тәмамланып, төннең башлануы турында белдерелгән һәм шуның белән кояшның тулысынча батуы аңлатылган. Бу, кемнең дә булса ялгышып, кояшның өлешчә баткан чагында ифтар кылмавы өчен әйтелгән. Яисә кеше кояшның батуын күрә алмаслык урында булырга мөмкин. Бу очракта көннең бетеп, төннең башлануы белән ул ифтарның җитүен аңлар.

Алюси тәфсирендә әйтелгәнчә, әлеге аятьтәге "...Сәхәр ашагыз, эчегез, хәтта таң якынлыгы беленгәнче..." җөмләсе рамазан уразасында көндез ниятнең рөхсәт ителгән булуын раслый. Чөнки Аллаһы Тәгалә ашауэчүне һәм җенси якынлык кылуны таң ата башлаганчыга кадәр рөхсәт иткән һәм шул вакыттан ураза тотарга кушкан.

Бу очракта "тәмам итегез" әмере "уразаны таң ата башлаганнан тотып, төнгә кадәр тәмам итегез" дигәнне аңлата.

Ураза тоту бары тик ашау-эчүдән тыелып торуны гына белдерми. Ураза тотучыга ният әйтергә кирәк. Ниятне көннең уртасына кадәр әйтергә мөмкин. Бигрәк тә бу изге аять уразаның бер-берсенә кушылып китмәвен (ягъни уразаның тоташ берничә тәүлек дәвамында булмыйча, төнлә өзелеп торуы кирәклеген) дәлилли. Чөнки Аллаһы Тәгалә: "...аннары уразаны тотып, тәмам итегез кояш баеганчы!" - диеп, төнлә уразаның өзелеп торуын белдергән.

Гайшә (радыйаллаһу ганһә) әйткән: "Рәсүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вәссәлам), өммәтенә мәрхәмәтле булуы сәбәпле, уразаларның бер-берсенә кушылып китүен тыйган".

Сахабәләрнең: "Син бер көннең уразасын икенче көннең уразасына кушып җибәрәсеңме?" - дип сораганнарына Рәсүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вәссәлам): "Минем яшәешем сезнеке кебек түгел (берегезгә дә охшамаганмын). Чөнки Раббым мине ашата да, эчертә дә", - дип җавап кайтарган" (Бохари, "Саум", 48, 2/232).

Бигрәк тә "уразаны ... тәмам итегез" дигән әмер уразаны кимчелекле итә торган хәрамнардан һәм гөнаһлардан тыелуның кирәклегенә ишарәли.

Төн белән көн алышынмыйча, алты ай буе төн булып, алты ай дәвамында көн булган җирләрдә уразаны ничек тотарга кирәк, дигән сорау белән җәфаланган кешеләргә: "Төн белән көн алышынмаган котыпларда һәм аларга якын җирләрдә яшәүче кешеләр уразаны үзләренә көн белән төн алышынган иң якын өлкәләрдәгечә тотарга тиеш. Вакыт шул өлкәләргә карап билгеләнә. Ягъни уразаны көн белән төн алышынган иң якын өлкәләргә карап тотарга кирәк".

## Ураза кайчан фарыз кылынган һәм фарыз булуының дәлилләре

Исламның биш шартыннан берсе булган ураза һиҗрәттән соң бер ел ярым вакыт узгач, шәгъбан аеның унынчы көнендә фарыз кылынган. Рамазан уразасының дәлилләре булып Коръән, Сөннәт һәм иҗмаг тора.

## Уразаның фарыз кылынуы турында аятьләр

"Әй, мөэминнәр! Сездән әүвәлгеләргә ураза тоту фарыз ителгән кебек, сезгә дә һәр елны бер ай ураза тоту фарыз ителде, шаять, уразаны калдырудан яки уразага кимчелек китерүдән сакланырсыз!" ("Бәкара" сүрәсе, 183 нче аять).

## Изге аятьнең тәфсире һәм аңлатмасы

● Әлеге аятьтәге "санаулы көннәр" сүзтезмәсе, аннан соңгы изге аятьтә ачык аңлатылганча, Изге рамазан аен белдерә.

● Бу аятьтә әйтелгәнчә, рамазан аенда хаста кеше яки унсигез сәгатьлек ераклыктагы сәфәрдә булган (нинди транспорт чарасы белән юлчылык кылуы мөһим түгел) кеше шушы сәфәрендә унбиш көннән азрак вакытка кала торган булса, боларга ислам ураза тотмауны рөхсәт иткән.

● Бу рөхсәттән шәригатьчә акланырлык сәбәбе булган кешеләр, ягъни хасталыклары яки сәфәрләре аркасында ураза тота алмаган кешеләр генә файдаланырга мөмкин. Алар калдырган уразаларын сәламәтләнгәч яки өйләренә әйләнеп каткач, бер көн тотмый калдырган уразага бер көн исәбеннән тотып каза кылалар.

● Чөнки ураза фарыз гайн гамәл санала, ягъни ураза һәркем өчен дә фарыз кылынган. Шуңа күрә дә, кичектерү рөхсәт ителсә дә, уразаны бөтенләй тотмый калдыру ярамый, казасын кылырга кирәк.

● Әмма сәламәтләнүе мөмкин булмаган хасталыкларга дучар ителгән кешеләрнең ураза тоту урынына фидия бирүләре рөхсәт ителгән. Гәрчә Ибн Әбү Ләйла (рахмәтуллаһи галәйһи) әйтүенчә: "Рәсүлуллаһ Мәдинә-Мөнәвәрәгә килгәч, сахабәләренә өч көн ураза тотарга әмер иткән. Соңыннан рамазан уразасының фарыз кылынуы турында вәхи иңдерелгән. Шушы вакытка кадәр гарәпләр ураза тотарга гадәтләнмәгәнгә күрә, ураза алар өчен бик авыр һәм мәшәкатьле тоелган. Шуңа күрә, берниндн акланырлык сәбәбе булмыйча ураза тотмаган кешеләр дә, фәкыйрьләрне ашатып, әлеге бурычны өсләреннән төшерергә тырышканнар.

Соңрак алдагы аятьләрдә китерелгән "Сездән рамазан аена ирешкән һәрберегез, әлбәттә, ураза тотсын!" әмере белән әлеге иреклелек бетерелгән. Ураза тотмау рөхсәте бары тик юлчы белән хасталарга гына бирелгән" (Әбү Дауд, "Саләт", 28; Әхмәд Ибн Хәнбәл, "Әл-Мүснәд", 5/246).

Шулай ук, әлеге изге аятьтән аңлашылганча, ул вакыттагы юлчыларның сәфәр кылу мөмкинлекләре дә бүгенге көндәге кебек уңайлы булса, ураза тотуларын үз өсләренә кайтарып калдыру хәерлерәк булыр иде. Чөнки сәфәрдә ураза тоту мәшәкатьле, кичектерүе рөхсәт ителгән. Мәшәкатьле гамәлнең яхшырак булуында шик юк. Аятьтә китерелгән "Сездән рамазан аена ирешкән һәрберегез, әлбәттә, ураза тотсын!" әмерендә сүз Изге рамазан ае турында бара. Шушы айда уразаны сәламәт акыллы һәм сәламәт тәнле, балигъ булган һәм үз ватанында даими яшәүче мөселманнар тотарга тиеш. Моннан алдагы аятьтә хаста, мөсафир (юлчы), мокыйм (үз ватанында яшәүче) һәм сәламәт булучылар турында ачыклык кертелгән. Әлеге аять исә хаста яки юлчы булмаган кешеләрнең, һичшиксез, ураза тотулары ваҗиб кылынуын ачыклый. Аларның фидия бирүләре турындагы хөкем бетерелгәнгә, шәригатьнең ураза тотмаска рөхсәте юлчы һәм хасталарга карата да бетерелгән дигән фикер тумасын өчен, юлчы белән хастаның ураза тотмаска рөхсәте тагын бер кабатланган. Бу очракта, сәламәт булып һәм юлчы булмаган кешенең ураза тотмавы рөхсәт ителми. Шушы уңайдан фикыһ китапларында болай диелгән: "Берәү Изге рамазан аенда бернинди акланырлык сәбәбе булмастан, ураза тотмыйча, ашаса һәм эчсә, исламның әдәпләрен бозган була һәм "тәгъзир-и шәргый"гә (шәригать нигезендә шелтәләнүгә) дучар ителә". Чөнки ураза тотарга теләмәү нияте белән рамазан аенда ашау-эчүгә кәффарәт таләп ителә. Шуңа күрә, ураза вакытында ашаган һәм шушы изге айга тиешле хөрмәт белән кадерне бозуы сәбәпле, шәригать хакименең шелтәләвенә дучар була. Мөселманнар тоткан ислам диненең гореф-гадәтләрен ихтирам итеп һәм саклап, ул җәмгыятьнең гармониясен һәм тәртипләрен бозмаска кирәк. Мөселманнарның тормышы нигезләнгән хөкемнәрне сакламау аларны рәнҗетергә һәм тормыш-көнкүрешләрен бозарга да мөмкин.

Бу аятьләрнең ахырында Аллаһы Тәгалә "Аллаһ сезгә җиңеллекне тели, авырлыкны теләми" дип әмер иткән. Моның белән Ул хасталарга һәм юлчыларга ураза тотмаска рөхсәт бирүе турындагы хөкемен белдергән.

## Уразаның фарыз булуына сөннәттән дәлилләр

Рамазан уразасының фарыз кылынуына сөннәттән дәлил итеп Пәйгамбәребезнең (саллаллаһу галәйһи вәссәлам) Ибн Гомәр (радыйаллаһу ганһү) тапшыруындагы сүзләрен китерәбез: "Ислам биш баганага нигезләнгән. (Болар:) Аллаһтан башка иләһ булмаганга һәм Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәламнең Аллаһ илчесе һәм колы булуына шаһитлык китерү, намаз уку, зәкят бирү, хаҗ кылу һәм рамазан аенда ураза тоту" (Бохари, "Иман", 2, №8 1/27; Мөслим, "Иман", 7, №16 1/29).

Талха Ибн Гобәйдуллаһ (радыйаллаһу ганһү) (болай дигән): "Бер гарәп чәчләрен тузгыткан килеш Рәсүлуллаһка (саллаллаһу галәйһи вәссәлам) иелеп әйтте: "Йә, Рәсүлуллаһ! Аллаһ минем өчен намаздан нәрсәне фарыз кылды. Миңа бу хакта сөйлә!" - дигәч, Рәсүлуллаһ (саллаллаһу галәйһи вәссәлам) аңа: "Биш вакыт намаз (фарыз кылынды), ләкин син үзлегеңнән берни дә кылмаска мөмкин", - дип кушты. Моңа каршы әлеге кеше: "Аллаһ минем өчен уразадан нәрсәне фарыз кылган, миңа шул турыда сөйлә!" - диде. Рәсүлуллаһ (саллаллаһу галәйһи вәссәлам): "Рамазан аен фарыз кылды, ләкин син үзлегеңнән уразаны тотмый да калдыра аласың", - дип җавап кайтарды. Теге кеше тагын да: "Аллаһның минем өчен зәкяттән фарыз кылганы нәрсә? Бу хакта да миңа сөйлә!" - дип сорады. Рәсүлуллаһ (саллаллаһу галәйһи вәссәлам) аңа исламның гыйбадәт юлларын (зәкят турында, аның микъдарлары, хаҗ һәм аның хөкемнәре хакында) сөйләде. Нәтиҗәдә, әлеге гарәп: "Сиңа хакыйкатьне өйрәткән Аллаһ белән ант итәм: мин үз ихтыярым белән берни дә кылмам, тик Аллаһ минем өчен фарыз кылган нәрсәләрнең берсенә дә кимчелек китермәм", – дигән. Моңа каршы Рәсүлуллаһ (саллаллаһу галәйһи вәссәлам): "Әгәр бу сүзләре дөрес булса, фәләх булды (әгәр дөрес сөйләгән булса, җәннәткә керәчәк)", - дигән (Бохари, "Иман", 35, №46; "Саум", 1; Мөслим, "Иман", 9).

Иҗмаг хакында: өммәт тулысынча рамазан ае уразасын фарыз буларак кабул иткәнгә, аны бары тик кяферләр генә инкарь итә.

Әһле Сөннәт вәл Җәмәгать фикеренчә, акланырлык сәбәбе булмаган килеш ураза тотмаучыга һәм теләсә кайсы гамәлне кире кагучыга кяфер тамгасы сугылмаса да, ураза кебек катгый күрсәтмәләр белән исбатланган диннең иң әһәмиятле хөкемнәреннән берсен инкарь итүчегә кяфер диләр. Кайберәүләрнең: "Аллаһ синең уразаңа мохтаҗ түгел" яки "Ураза гап-гади диета бит ул. Мин болай да аз ашыйм, ураза тотуым нигә кирәк", - дигән сүзләре, һичшиксез, "әлфази күфүр", ягъни сөйләүчене кяфер итәчәк сүзләр була. Шулай ук ураза тотучыларны бу рәвешле мыскыллаган һәм хурлап көлгән кебек ашау һәм эчү дә исламны һәм мөселманнарны түбәнсетү була һәм әлеге кешеләр көферлеккә төшәләр.

## Рамазан уразасының фарыз булуы хикмәтләре

Уразаның канунлаштырылуында шактый хикмәтләр бар:

а) ураза - бирелгән нигъмәтләр өчен шөкер итү чарасы. Нигъмәтләр өчен шөкер итү акыл белән дә, шәригать буенча да фарыз. Мәсәлән, Аллаһы Тәгалә ураза турындагы аятьтә "Шаять, Аллаһка шөкер итәрсез!" - дип әмер итеп, шуңа ишарәләгән;

ә) ураза фәкыйрьләргә мәрхәмәтле һәм шәфкатьле булырга өйрәтә. Байларга ел буе ач торган фәкыйрьләрнең хәленә төшенергә ярдәм итә;

б) уразаның рухи саваплары, гөнаһлардан саклану кебек фазыйләтләре дә бар, гәүдәне чистарту (арындыру) һәм кайбер хасталыклардан саклау кебек матди файдалары да бар.

Уразаның ашказанын сәламәтләндерүе һәркемгә мәгълүм. Мәсәлән:

Әбү Һурәйрадан (радыйаллаһу ганһү) риваять ителгәнчә, бер хәдистә Рәсүлуллаһ (саллаллаһу галәйһи вәссәлам): "Ураза тотыгыз, сәламәт булыгыз", - дип әмер иткән (Ибн Сунни, Әбү Нугайм, "Әт-Тыбб"; Нәбхани, "Әл-Фәтхул Кәбир", №7301, 2/25);

в) ураза шәһвәтне (җенси теләкләрне) тыя. Чөнки күзгә матур булып күренгән нәрсәләр җенси теләкләрне уята. Ач торганда исә тыелып калып була.

Бу очракта ураза гөнаһлардан сакланырга ярдәм итүче чара. Мәсәлән, Абдуллаһ (радыйаллаһу ганһү) болай дип аңлаткан: "Без Пәйгамбәребезнең (саллаллаһу галәйһи вәссәлам) кулы астындагы бер төркем яшьләр идек. Тик безнең өйләнергә бернинди мөмкинлегебез дә юк иде. Рәсүлуллаһ (саллаллаһу галәйһи вәссәлам) безгә: "Әй, яшьләр! Өйләнергә мөмкинлеге булганыгыз өйләнсен. Чөнки өйләнү күзне хәрамнан саклый торган иң яхшы чара һәм җенси әгъзаларны да саклый. Өйләнергә көчегездән килмәсә, ураза тотыгыз. Чөнки ураза кешенең җенси теләкләрен тыярга ярдәм итә", - дип боерды (Бохари, "Никах, 2, 3, 6/117, "Саум", 20; Мөслим, "Никах", 1, 3; Әбү Дауд, "Никах", 1; Тирмизи, "Никах", 1; Нәсаи, "Сыйам", 43, "Никах", 3; Ибн Мәҗа, "Никах", 1; Дарими, "Никах", 2; Әхмәд Ибн Хәнбәл, "Әл-Мүснәд", 1/378, 424, 425, 432, 447).

Хәдистә китерелгән "әл-Вәҗ" сүзе "уау"ның фәтхәсе һәм "җим"нең сүкүне белән язылганда, кул белән сугу, хәнҗәр һәм пычак белән чәнчү, җәрәхәтләү мәгънәсен дә белдерә, җенси якынлык кылуны да аңлата.

"Вәҗәгъ" китап телендә кучкар яки тәкәнең күкәйләрен чыгармыйча, күкәй тамырларын ике таш арасында кысып кире кертү дигән мәгънәдә килә. Бу очракта күкәйләргә зыян килми. Әлеге сүз күкәйләрне изеп бетергәнче төюне белдерә.

Дин галимнәре фикеренчә, җенси теләкне тыю өчен, көндез ураза тотарга, ә төннәрен гыйбадәт кылырга кирәк. Чөнки ураза һәм гыйбадәтләр җенси теләкләр турында онытырга ярдәм итә. Әгәр син: "Бер кеше ураза тота, төнлә тора, күп ашамый. Әмма нәфесе һаман да җенси теләкләрдән аерылмаган була", - дисәң, "Бу, беренче чиратта, җенси теләкләрнең артык булуыннан килә. Мондый кешегә без җенси теләкләрен тыю өчен даими кайгы-хәсрәтләр һәм үлем, әҗәлнең якынайганы турында уйланырга, озын гамәлләрне кыскартырга, Раббыбызны күргәндәгедәй халәтләрен дәвам иттерергә һәм гыйбадәтләрен дәвамлы рәвештә кыскартырга тырышуын киңәш итәбез".

Шуны белергә кирәк: барлык кешеләрнең дә тырышулары ике төрле нәрсәгә бәйле:

1. Ашау-эчү теләге.
2. Җенси теләк.

Уразаның, әлеге ике теләкне тыеп, кешене тәкъвалыкка ирештерүеннән шикләнергә ярамый;

г) Ураза тәкъвалыкка илтә. Чөнки ураза тоткан кеше Аллаһы Тәгаләнең үзенә хәләл итеп биргән нигъмәтләреннән бары тик Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешүне өметләнә, хәсрәткә төшерүче газапларыннан куркып, үзен тоткарлый алганча тоткарлый, тыя алган кадәр тыя.

Аллаһы Тәгалә хәрам кылган нәрсәләрдән үзен саклау, һичшиксез, тагын да яхшырак була. Тәкъвалык шушы була инде.

Мәсәлән, ураза турындагы аятьнең ахырында Аллаһы Тәгалә: "Шаять, Аллаһка шөкер итәрсез!" - дип әмер иткән.

Раббыбыз "Бәкара" сүрәсенең 21 нче аятендә: "Әй, кешеләр! Сезне һәм сездән элек булган кешеләрне халык кылучы Аллаһка гыйбадәт кылыгыз! Аллаһ газабыннан куркучы булу өчен", - дип әмер иткән. Югарыда искә алган ураза турындагы аятьтә дә: "Әй, мөэминнәр! Сездән әүвәлгеләргә ураза тоту фарыз ителгән кебек, сезгә дә һәр елны бер ай ураза тоту фарыз ителде, шаять, уразаны калдырудан яки уразага кимчелек китерүдән сакланырсыз!" - дип боерылган ("Бәкара" сүрәсе, 183 нче аять).

Бу аятьләрдән аңлашылганча, барлык гыйбадәтләрнең дә, бигрәк тә, уразаның дәвамлы булуыннан тәкъвалык барлыкка килә. Ягъни барлык гыйбадәтләрне дә дәвамлы башкарган кеше тәкъвалыкка (Аллаһтан куркуга, Аллаһны ихтирам итүгә) ирешә. Димәк, гыйбадәт кылмаган кешеләр тәкъва булмый. Чөнки тәкъва - гыйбадәтнең нәтиҗәсе. Бигрәк тә бу аятьләрдән тәкъвалыкка ирештермәгән ураза һәм башка гыйбадәтләрнең Аллаһ каршысында рөхсәт ителмәве аңлашыла. Мәсәлән: Әбү Һурәйрадан (радыйаллаһу ганһү) риваять ителгән бер хәдистә Рәсүлуллаһ (саллаллаһу галәйһи вәссәлам) болай дигән: "Ялган сөйләүдән һәм ялган белән гамәл кылудан туктамаган кешенең, ураза тотам дип, ашау-эчүеннән калуына Аллаһ мохтаҗ түгел" (Бохари, "Саум", 8, 2/228).

Әнәс Ибн Мәлик (радыйаллаһу ганһү) тапшырган бер хәдистә Пәйгамбәребез (саллаллаһу галәйһи вәссәлам: "Кешеләрнең итләрен ашаган (гайбәт сөйләгән) ураза тотмадылар", - дип әйткән (Дәйләми, "Мүснәди Фирдәүс", 4/77, №6238).

Әбү Һурәйрадан (радыйаллаһу ганһү) риваять ителгән бер хәдистә Рәсүлуллаһ (саллаллаһу галәйһи вәссәлам) әйткән: "Ураза ашау белән эчүдән генә өзелеп тору түгел ул. Ураза кирәкмәгән сүзләрдән һәм гамәлләрдән, җенси теләкләрне кузгатучы сүзләр һәм гамәлләрдән тыелуны да белдерә. Әгәр бер кеше сине сүгәргә яки сиңа каршы белмичә хәрәкәт итә башласа, син "мин ураза тотам (синең сүзләреңне ишетмәм)" дип әйт" (Хаким, "Мүстәдрәк", 1/430).

Әбү Һурәйра (радыйаллаһу ганһү) тапшырган бер хәдистә Пәйгамбәребез (саллаллаһу галәйһи вәссәлам): "Дөньяда никадәр ураза тотучы бар, тик аларның уразалары (хәрамнан сакланмаганнары сәбәпле) бары тик ач торудан гыйбарәт. Дөньяда төннәрен торып никадәр намаз укучы бар, тик аларның кыямнары бары тик йокысызлык булып кына кала", - дип әйткән (Хаким, "Мүстәдрәк", 1/431).

Әнәс Ибн Мәликтән (радыйаллаһу ганһү) риваять ителгәнчә, Пәйгамбәребез (саллаллаһу галәйһи вәссәлам) бер хәдистә: "Биш нәрсә ураза тотучының авызын ачтырыр (савабын бетерер) һәм тәһарәтен(ең камиллеген) бозар. (Болар): ялган, гайбәт, сүз ташу, җенси теләк белән карау һәм ялганлап ант итү", - дип кисәткән (Зәбиди, "Итхаф", 4/245; Суйути, "Әл-Леали", 2/60; Гәйлани, "Әл-Гунья", 1/333).

Әбү Һурәйра (радыйаллаһу ганһү) әйткән: "Гайбәт уразаны ертa, истигъфар (гафу итүне сорау) аңа ямаулык сала. Һәркайсыгыз, иртәгә ахирәткә уразасы ямалган килеш барырга көченнән килсә, моны эшләргә тырышсын".

Җәбир Ибн Габдуллаһ (радыйаллаһу ганһү) болай дигән: "Ураза тотканда, колагың, күзең һәм телеңне ялганнан һәм барлык хәрамнардан тый (үзеңне сакла). Хезмәтчеләреңне дә җәберләмә, уразалы көнеңдә авыр сабырлы һәм тыныч бул, уразалы көнең белән ураза тотмаган көнең охшаш булмасын".

Әбү Зарр (радыйаллаһу ганһү) әйткән: "Ураза тотканда, хәрамнардан көчең җиткән кадәр сакланырга тырыш".

Үзе дә ураза тоткан көннәрендә өенә кайтып гыйбадәт кыла торган булган, бары тик намазларга гына өеннән чыккан.

Имам Мөҗаһид (рахмәтуллаһи галәйһи) әйткән: "Ике сыйфат бар. Алардан сакланган кешенең уразасы бозылмас. Болар - гайбәт һәм ялган".

Әбүл Алийә дә: "Ураза тоткан кеше гайбәт сөйләгәнчегә кадәр гыйбадәтендә булыр", - дигән (Суйути, "Дүррүл Мәнсур", 1/484).

Хөзәйфа Ибн Яман (радыйаллаһу ганһү) болай дигән: "Узып барган хатын-кызның артыннан нәфесле күз белән карап калган кешенең уразасы бозылыр" (Гәйлани, "Әл-Гунья", 1/334).

Ураза тотучы кешегә, дөнья һәм ахирәтен югалтмау өчен, әдәп сакларга, уразасын күрсәтмәлелектән һәм кеше сүзеннән сакларга, барлык гыйбадәтләрен дә тиешенчә үтәргә кирәк. Чөнки Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен кылынмаган, бары тик кешеләргә күрсәтү өчен генә эшләнгән гамәлләр бик күп газапларга дучар итәләр.

Рәсүлуллаһның (саллаллаһу галәйһи вәссәлам) догасын китерәбез: "Әй, Аллаһым! Телемне ялганнан, йөрәгемне икейөзлелектән, гамәлләремне риядан (кешеләргә күрсәтү өчен эшләүдән) һәм күзләремне хыянәтле караудан пакьлә! Чөнки Син күзләрнең хыянәтен һәм йөрәкләрнең серен беләсең!" (Зәбиди, "Итхаф", 7/514; Хатиб, 5/268; Мишкәт, №2501).

**"Хузур" нәшрият йортында басылып чыккан "Ураза" китабыннан**

# УРАЗАНЫҢ МАКСАТЫ

**Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-ражииим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил гааләмииин вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил кәрим үә галәә әәлиһи үә әсхабиһи әҗмәгыйн.**

**"... Аллаһы сезгә җиңеллек тели, авырлык теләми..." ("Бәкара *(Сыер)" сүрәсе, 185 нче аять).***

Ураза кешегә ни бирә?

Мөселман иртәдән кичкә кадәр ашамыйча-эчмичә, җенси теләкләрен тыеп, уразасын фарыз шартларга туры килерлек итеп тотып та, көтелгән файдага ирешмәве дә мөмкин. Беренче чиратта шуны әйтергә кирәк: уразаны Аллаһы Тәгалә әмер иткәнлектән, Аның ризалыгы өчен тотабыз. Шул ук вакытта без әлеге әмерне үтәгәндә ниндидер файдага да ирешәбез. Чөнки Аллаһы Тәгалә безгә ни генә әмер итсә дә, аларның барысында да безнең өчен дөньяви вә рухи файда бар. Югыйсә безнең аларны кылып-кылмавыбыздан Аллаһы Тәгалә бернинди файда ла, зыян да күрми. Гомумән, безнең ач торуыбыз Аллаһыга кирәкме?Аллаһы галәмдәге бер нәрсәгә дә, бер мәхлукка да мохтаҗ түгел. Аллаһы Тәгалә үзенең әмерләрен колларына золым, авырлык һәм кыенлык теләп бирмәгән.

**"... Аллаһы бәндәләренең һәрберсенә золым теләми" ("Әли Гыймран *(Гыймранның гаиләсе)" сүрәсе, 108 нче аять).***

Димәк, Аллаһы Тәгалә безгә ни генә әмер итсә дә, алар барысы да, чыннан да, безнең матди вә рухи ягыбызны карау өчен әмер ителгән. Әмма без бары Аллаһ кушканлыктан һәм Аның ризалыгын алыр өчен генә гыйбадәт кылабыз. Мондый зур файдалы мөмкинлекне әмер иткәне өчен Аллаһы Тәгаләгә шөкер итсәк иде.

Аллаһы ризалыгы өчен тоткан уразабыз матди вә рухи файдага ирешә алсын өчен нәрсәгә игътибар итәргә кирәк соң? Бу хакта исламның бөек галиме вә күренекле фикер иясе **имам Газзәли "Ихйа-у Улуми-д Дин"** исемле хезмәтендә язып калдырган. Ислам динен яхшы белгән һәм Аллаһы кушканча яшәргә омтылган мөселманның уразасы түбәндәгечә булырга тиеш:

**1. Уразалы кеше үзенең күзләрен һәртөрле яманлыклардан сакларга тиеш.**

Күз зинасыннан сакланырга кирәк. Башкаларның малына, намусына яман күз белән карарга ярамый. Кемнеңдер малына кызыгып карау тыела. Боларның барысын да Аллаһы Тәгалә бирә бит.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үенең бер хәдисендә болай дигән: "Күзләрен хәрам белән тутырган кешенең Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә күзләрен ут белән тутырыр".

**2. Колакларын һәртөрле яман сүзләр ишетүдән сакларга тиеш.**

Ураза тотучы колакларын яман сүзләргә шаһит булудан сакларга тиеш. Моның өчен аңа яман сүзләр сөйләшүче кешеләр янында утырмаска кирәк. Ул берәр мәҗлестә динне мәсхәрәләү, сүгү һәм мыскыл итүгә шаһит булса, андагы кешеләрне бу хакта сүз катудан туктатырга яисә алар яныннан чыгып китәргә тиеш.

**3. Телен һәртөрле ялган вә яман сүзләр сөйләүдән, ялган антлар бирүдән, буш сүзләрдән сакларга тиеш.**

Коръәни-Кәримдә Аллаһы Тәгалә болай дип боера:

**"... Ялган сүздән саклангыз" *("Хаҗ" сүрәсе, 30 нчы аять).***

"Әй, мөэминнәр, Аллаһыдан куркыгыз! Сөйләгән вакытта чын дөресен генә сөйләгез" ("Әхзаб (Гаскәрләр)" сүрәсе, 70 нче аять).

Әбү Һурайрадан (Аллаһы Тәгалә аннан разый булса иде) риваять ителә ки, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: *"Аллаһыга һәм Кыямәт көненә (аның хаклыгына, котылгысызлыгына) ышанган кеше яхшы сүз сөйләсен яки эндәшмәсен!" (Бохари).*

**1.Мөселман кеше барлык әгъзаларын да яман гадәтләрдән сакларга тиеш.**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: "Бер кеше башкаларның яман сүзләрен вә гамәлләрен кире какмаса, "ураза тотам" дип ашамый-эчмичә һәм җенси теләкләрен тыеп торуыннан бернинди дә файда булмас. Бары фарызы гына үтәлгән булыр" (Бохари).

**2. Ифтар вакытында күп ашарга ярамый.**

Кояш батканчы буш торган ашказанын кисәктән шыплап тутырып кую сәламәтлеккә файда бирмәс. Моны медицина фәне дә раслый. Асылда ахшамга азан әйтелгәч, берничә хөрмә һәм зәйтүн җимеше яисә бер стакан су белән авыз ачарга кирәк. Аннары ахшам намазы укыла. Намаздан соң ифтар ризыгыннан авыз ителә. Ләкин бик күп ашап куюдан сакланырга кирәк.

**3. Ураза тотучы ифтар кылганда курку белән өмет арасында булырга тиеш.**

"Мин бүген ураза тоттым, әмма ул кабул ителмәде", - дип өметсезлеккә, куркуга бирелергә ярамый. Мөселман кеше беркайчан да Аллаһының рәхмәтеннән өметен өзмәс: "...Аллаһының рәхмәтеннән өмет өзмәгез, чөнки тәүбә итеп төзәлгәндә, Аллаһы гөнаһларны ярлыкаучыдыр, Ул (Аллаһы) ярлыкаучы вә рәхимле" ("Зүмәра (Халык төркеме)" сүрәсе, 53 нче аять).

Ләкин: "Аллаһы ничек тә гафу итәр әле", "Ураза тотам, кабул ителгәндер", - дип нык ышаныч белдерергә дә кирәкми. Чөнки Аллаһы тели икән - гафу итә. Теләми икән - гафу итми. Берәү дә Аллаһыны гафу итәргә мәҗбүрили алмый. Шуңа күрә ураза тотучы өмет белән курку арасында булырга тиеш. Уразаны Аллаһы ризалыгы өчен тотарга тырышырга кирәк. "Кабул булмаса нишләрмен", - дип курку тиешле. Шул ук вакытта уразаң кабул булсын өчен Аллаһыга дога кылырга кирәк.

Рамазан-шәриф - Аллаһының Китабы Коръәни Кәрим иңгән ай, ягъни Коръәнне уку, өйрәнү, аның аятьләре, сүрәләре турында уйлау, фикер йөртү һәм, әлбәттә, Коръән буенча яшәү ае. Аллаһы Раббыбыз Коръәндә болай дип әйтә: "Рамазан ае - кешеләргә тугры юл күрсәтүче, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр" ("Бәкара (Сыер)" сүрәсе, 185 нче аять).

Коръән укуның фазыйләтләре турында сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дигән: "Коръән укыгыз, чөнки Аллаһының Китабыннан укылган һәрбер хәреф өчен ун савап биреләчәк, мин әлиф-ләм-мим бер хәреф дип әйтмим, чөнки аларның һәрберсе аерым хәреф, аларның барысы өчен дә унар савап биреләчәк" (Тирмизи).

Әбү Һурайра (Аллаһ аннан разый булса иде) риваять кылганча, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: "Әгәр бер кеше мөселман кардәшен бер кайгысыннан арындырса - Кыямәт көнендә Аллаһ ул бәндәне бер кайгысыннан арындырыр. Әгәр бер кеше бер фәкыйрьнең хәлен җиңеләйтсә - Аллаһы аның хәлен бу дөньяда да, ахирәттә дә җиңеләйтер. Бер кеше үзенең кардәшенә ярдәм иткәндә Аллаһы аңа Үзенең ярдәмен дә ирештереп торыр. Гыйлем алу юлына баскан кешегә Аллаһы җәннәт юлын җиңеләйтер. Кешеләр Аллаһ йортына җыелып, Аның Китабын укыганда мөселманнарның җаннарына тынычлык иңәр, алар бәрәкәтле булыр вә фәрештәләр алар өстендә канатларын җәеп торыр. Алар Аллаһы Тәгаләгә якын булыр" (Мөслим, Әбү Дауд, Тирмизи, Ибн һәм Маҗәһ).

Әгәр мөселман кешесе көндез ураза тотса, төннәрен Коръән укыса, Кыямәт көнендә аның ике яклаучысы булачак. Алар мөселманнарга Аллаһыдан ярлыкау һәм җәһәннәм утыннан котылу сораячак. Шул ике яклаучының берсе - ураза, икенчесе - Коръән булыр. Хәдистә әйтелгән: "Ураза һәм Коръән Хисап көнендә Аллаһының колын яклаячак. Ураза әйтер: "Йә, Раббым, көндез мин аны ризыксыз вә сусыз тилмерттем, шунлыктан мин аның өчен Синнән ярдәм сорыйм". Коръән әйтер: "Йә, Раббым, мин аны төнге йокысыннан калдырдым, шуңа күрә аңа Үзеңнең рәхмәтеңне ирештерсәң иде". Аларның үтенечләре кабул ителәчәк" (Әхмәд ибне Хәнбәл, Мүснәд).

Ибн Габбас (Аллаһ аннан разый булса иде) риваять кылган: "Җәбраил галәйһиссәлам рамазан аеның һәр төнендә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам белән очрашып, аның белән бергә Коръән өйрәнгән" (Бохари, Мөслим).

Кадерле мөселманнар! Аллаһы Раббыбыз безгә дә рамазан аеның төннәрендә уяу торып, Аллаһының Китабын укып, Аның бетмәс-төкәнмәс әҗер-савапларына ирешергә насыйп итсә иде.

Рәсүл Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләм икенче бер хәдисендә болай дигән: "Ике төрле кешедән генә көнләшергә ярый: беренчесе - Аллаһы Тәгалә Коръән байлыгы биреп, шуның белән көн-төн мәшгуль булучыдан; икенчесе - Алаһы Тәгалә күп нигъмәтләр биреп, шул байлыгын изге юлда сарыф итүчедән" (Бохари, Мөслим).

Аллаһы Раббыбыз һәрбарчаларыбызга да Коръән буенча яшәп, ике дөньяда да бәхетсәгадәткә ирешүчеләрдән булырга насыйп итсә иде.



**ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге**

# ХӘЗРӘТКӘ СОРАВЫМ БАР

***"Мөхтәрәм "Дин вә мәгыйшәт" газетасы хезмәткәрләре! "Юлдаш" газетасының "Дин вә йола" сәхифәсендә (28 март саны) Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләре китерелә.***

***1. Әгәр берәр кеше "Йәсин" сүрәсен укыса, аңа Коръәнне ун мәртәбә хәтем кылганның савабы булыр, диелә.***

***2. Хәзрәти Әнәс тапшырган хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, "Насыр" сүрәсен уку Коръәннең дүрттән бер өлешен укуга тиң, дигән.***

***3. Хәзрәти Әнәс тапшырганча, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: "Рәҗәптә бер көн ураза тоткан кешенең уразасы бер еллык ураза шикелле булыр. Җиде көн буенча ураза тотучы алдында җәһәннәмнең җиде капкасы бикләнер. Сигез көн уразада булса, аңа җәннәтнең сигез капкасы ачылыр", - дигән.***

***Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, авырайтмагыз, җиңеләйтегез, дигән бит. Шуңа күрә айлар буе ураза тотканчы, 8 көн ураза тотарга да җәннәткә керергә, дип аңларга микән моны?***

***Шушы сорауларга без аңларлык итеп җавап бирсәгез, бик рәхмәтле булыр идем.***

Сезгә уңышлар теләп,
Салих ЗИННӘТОВ,
Зәй районы, Аксар авылы."



**Сезнең сорауга Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе, Апанай мәчете имам-хатыйбы Нияз хәзрәт Сабиров җавап бирә:**

- Бу хәдисләрдә аерым сүрәләрнең, нәфел уразаларының фазыйләтләре, әҗерләре турында әйтелгән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шундый хәдисләр белән безне өстәмә изге гамәлләр кылырга чакыра. "Авыраймагыз, җиңеләйтегез" дигән сүзләр дингә, Коръәнгә һәм сөннәткә туры килмәгән гамәлләрне кертмәгез, дигәнне аңлата. Без, мөселманнар, шуны яхшы аңларга тиеш: Аллаһы Тәгалә кайбер гамәлләрне безгә фарыз (тиешле) кылды, ул гамәлләрне үтәмичә, нәфелләрен генә кылсак, Аллаһы Тәгалә каршында гөнаһлы булачакбыз. Мәсәлән, Изге рамазан аенда фарыз уразаны тотмыйча, рәҗәп яки шәгъбан аенда гына берничә көн ураза тотып, җәннәтле булырга өметләнү. Раббыбыз Аллаһ Коръәндә болай дип әйтә: "Аллаһ беркемгә дә көче җитмәслекне йөкләмәс" ("Бәкара" сүрәсе, 286 нчы аять). Һәр кеше фарыз гамәлләрне үти ала, моның өчен бары тик Аллаһның барлыгына, берлегенә ихлас иман һәм белем генә кирәк.

Шулай итеп, һәр мөселманның беренче вазыйфасы фарыз гамәлләрне үтәү, аннары гына нәфел гыйбадәтләр кылу.

Аллаһы Тәгалә барчабызга Аның кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып, ике дөнья бәхет-сәгадәтенә ирешергә насыйп итсә иде.

# КАДЕР КИЧЕ

**"Кадер киче, мең айдан да хәерлерәк савабы, мең ай кылган гыйбадәттән артыгractыр"** ***("Кадер (Кадер кич)" сүрәсе, 3 нче аять).***

Кадер кичәсендә ике мөһим вакыйга булган: Мөхәммәд галәйһиссәламнең пәйгамбәрлек вазыйфасы шушы кичтә башланган һәм Изге Китабыбыз Коръәни Кәримнең беренче аятьләре иңдерелгән.

Кадер кичәсе рамазан аеның соңгы ун көне арасындадыр. Аның төгәл көне билгеле түгел. Ислам галимнәре, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең кайбер хәдисләренә таянып, бу кичә - рамазанның 26-27 нче киче, дип исәплиләр. Бер хәдистә болай диелә: "Кадер кичәсен рамазанның актыккы ун көне арасыннан, бигрәк тә так кичләрдән эзләгез".

Бу кичәнең яшерен калынуының хикмәте бар. Моның максаты - рамазандагы һәр кичне Кадер кичәсе шикелле гыйбадәттә үткәрергә өндәүдер. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм рамазан аенда гыйбадәт һәм догаларын тагын да арттыра, бигрәк тә рамазанның соңгы ун көнендә бик аз йоклый, көне-төне гыйбадәт кыла торган була. Бәлки, мөселманнар да бу ун көнне мөмкин кадәр изгелекләрен, гыйбадәтләрен арттырсыннар, дип Кадер кичәсенең төгәл вакыты сер булып каладыр.

Кадер киченең билгеләре түбәндәге хәдисләрдә хәбәр ителә:

"Кадер киченең билгеләрен санап чыгыйк: төн ап-аяз, ай күкнең уртасына килгән кебек була. Һава тыныч. Бу төндә салкын да, кызу да булмас. Йолдызларның атылуы да күзәтелми. Иртән кояш ялтырамыйча гына чыга. Шул көнне шайтанга кояш белән бергә чыгарга рөхсәт ителми".

"Кадер кичәсе салкын да, кызу да булмас. Бу - тыныч һәм аяз төн. Шул төндә ай ялтырый".

Кадер кичәсен ничек үткәрергә?

"Кем Кадер кичәсендә, савабы булырына ышанып, ихлас күңелдән гыйбадәт кылса, шуның үткәндәге гөнаһлары ярлыканыр", - дип әйткән Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам.

Кадер кичәсен каршылаганда түбәндәге киңәшләргә игътибар итегез:

- Кадер кичәсендә гыйбадәттә булырга, укылмаган намазларны каза кылырга, нәфел намазларын укырга кирәк;
- Коръән укырга, укыганнарын тыңларга кирәк;
- Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтергә, аның шәфәгатен өмет итәргә, аның өммәтеннән булуны яхшылап аңларга кирәк;
- вәгазь һәм нәсыйхәт тыңларга, калебне биләгән гафиллек томаннарын таратырга кирәк;
- тәүбә һәм истигъфар итәргә, хаталарны кабатламаска, туры юлга басарга тырышырга кирәк;
- зикер итәргә кирәк, чөнки Аллаһы Тәгаләне зикер итү белән калебләр тынычлыкка ирешә, кешедә иман куәтләнә;
- ихластан дога кылырга кирәк.

# ТӘРАВИХ НАМАЗЫ

**Рамазан аенда һәркөнне ястү намазыннан соң витр намазына кадәр тәравих намазын уку ирләргә дә, хатыннарга да сөннәт.**

Тәравих намазы бары 20 рәкәгатьтән тора. Икешәр рәкәгать ун намаз итеп яки дүртәр рәкәгать биш намаз итеп укыла. Бу намаз ялгыз да укыла, әмма җәмәгать белән мәчеттә уку сөннәт санала.

Тәравих намазын җәмәгать белән укыганнан соң витр намазы да җәмәгать белән укыла. Имам тәравих намазының да, витрның да кыйраәтләрен кычкырып укый.

Тәравих намазын түбәндәгечә ниятлиләр: "Ният кылдым ике рәкәгать тәравих намазын үтәмәккә, оедым ошбу имамга, халисан лилләһи тәгалә, Аллаһу әкбәр".

Тәравих намазлары арасында дүрт рәкәгать укыган саен - дүрт рәкәгатьле намаз укыган кадәр вакыт туктап "тәравихә" кылу, ягъни ял итеп тору - сөннәт.

"Тәравихә" вакытында тәсбих я тәһлил әйтеп, яки әйтелгәнне тыңлап утыру - мөстәхәб.

Без яши торган төбәктә "тәравихә" вакытында түбәндәге тәсбих әйтелә:

Субхәәнә зил-мүлки үәлмәләкүүт. Субхәәнә зил-гиззәти үәл-гәзамәти үәл-кудрәти үәлкибрийә'и үәл-җәбәрuут. Субхәнәл-мәлики-хәййил-ләзи лә йәмүт. Суббухүн куддүүсүр-раббил-мәләә'икәти үәр-руух. Ләә иләәһә ил-ләллаһү нәстәгфирул-лааһ. нәс'әлүкәл-җәннәтә үә нәгүүзү бикә минән-наар.

Мәгънәсе. Җирдәге һәм күктәге мәхлукатның хуҗасы булган Аллаһы Тәгаләне данлыймын. Көч, кодрәт һәм бик олуглык иясе булган Аллаһы Тәгаләне данлыймын. Бөтен галәмнең патшасы һәм беркайчан үлмәячәк, һәрвакыт терек булучы Аллаһы Тәгаләне данлыймын.

Ул Аллаһы Тәгалә бөтен кимчелекләрдән бик пакь һәм мөкаддәс Зат, бөтен фәрештәләрнең һәм Җәбраил фәрештәнең Раббысы. Бер Аллаһы Тәгаләдән башка илаһи зат юк. Без гөнаһларыбызның ярлыкавын сорыйбыз. Йә Рабби, без Синнән җәннәтне сорыйбыз һәм тәмугтан Сиңа сыгынабыз.

Тәравих намазлары тәмам булып, бишенче тәсбих әйтелгәннән соң, түбәндәге дога укыла:

Әллааһүммә салли гәләә Мүхәммәдин үә гәләә әәли Мүхәммәдин үә сәллим. Әллааһүммә зәййиннәә бизиинәтилиимән. Үә шәррифнәә бишәраафәтил-һидәәйәти үәлгирфәән. Үә әкримнәә бисыйаами шәһри рамәдаан. Үәрзүкънәл-җәннәтә үәл-гүфраан.



Үә тәкаббәл миннәә тәраауиихәнәә йәә сүбөхән. Үәс-тәҗиб дугааәнәә йәә хәннәән. Бифәдъликә үә җүүдикә йәә мәннаан. Бирәхмәтикә йәә әрхәмәрраахимиин.

Мәгънәсе. Йә Рабби, Мөхәммәд галәйһиссәләмгә, аның әһленә (гаиләсенә), рәхмәтеңне һәм сәләмеңне бир. Йә Рабби, безне иман зиннәте белән зиннәтлә, гыйлем һәм тәүфикъ белән кадерлә һәм рамазан ае уразасы белән хөрмәтле ит. Безгә җәннәтне һәм ярлыкауны насыйп ит. Әй пакь булучы Аллаһ, безнең тәравих намазларыбызны кабул кыл, әй Рәхмәтле Раббыбыз һәм сорамыйча бирүче Аллаһ, фазыйләтең һәм юмартлыгың белән безнең догаларыбызны кабул кыл. Әй камил рәвештә Рәхмәтеңне бирүче Аллаһ, һәрнәрсә Синең рәхмәтең белән генә була.

Тәравих намазының һәр рәкәгатендә "Фатиха" сүрәсеннән соң бер кыска сүрә укыла. "Кәлям Шәриф"нең (Коръәннең) башыннан алып, һәр рәкәгатендә куша-куша, берничә тәравихтә ахырына кадәр укып чыгып, Коръәнне хәтем кылу (тулысынча уку) олуг сөннәт булып тора.

Тәравих намазын ястү намазын укыганнан соң уку - сөннәт, шуның өчен мәчеткә тәравих намазы укыла башлагач килгән кешегә, иң әүвәл ялгызы гына ястү намазының дүрт рәкәгать фарызын уку һәм аннан соң тәравих намазын ниятләп, имамга ою тиешле.

Намазга соңарган кеше тәравихның калган рәкәгатьләрен имамнан соң ялгыз укып тәмамлый. Әгәр имам витрны укып бетергәнче тәравихны тәмамласа, имамга мәсбук (мәсбук - намазның иң аз дигәндә бер рәкәгатен калдырган һәм беренче рәкәгатьнең рөкугыннан соң гына кушылган кеше. Ул имам ике якка сәлам биргәннән соң торып баса һәм намазның үтәлми калган өлешләрен, кыйраәт рөкенен үтәп, укып бетерә) булып ойый. Әгәр дә тәравихны тәмамлаганчы имам витрны укып бетерсә, витрны да ялгыз укый.

**Әхмәтһади МАКСУДИның "Гыйбадәте исламия" китабыннан.**

# БОЛГАР ҖИРЕ ИЛЕБЕЗ БЕРЛӘШТЕРЕП

## Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның Идел буе Болгар дәүләтенең Исламны рәсми кабул итү көне уңаеннан

## МӨРӘҖӘГАТЕ

**Мөхтәрәм татарстанлылар!**

21 майда республикабызда истәлекле дата - Идел буе Болгар дәүләтенең исламны рәсми кабул итү көне бәйрәм ителә. 922 елны бабаларыбыз Аллаһы Тәгалә ярдәме белән тарихи адым ясый һәм без гасырлар дәвамында динебезгә тугры калып, борынгы бабаларыбыз традицияләрен зурлауны, саклауны дәвам итәбез. Ислам динен рәсми кабул итү көне ул, мөселманнарның Россиядә җирле халык булуына да бер дәлил. Күп гасырлар дәвамында илебездә мөселманнар өммәте динебезгә таянып эш йөртә, тормышларын алып бара.

Ислам безне гаделлеккә,зирәклеккә, изгелек кылырга, мәрхәмәтле һәм югары әхлаклы булырга өйрәтә. Шуның өчен динебез Россия халыклары арасында киң таралыш ала. Тарихыбыз, гореф-гадәтләребез, мәдәниятебез, телебез ислам белән үрелгән.

Татар халкы һәрвакыт үзенең гыйлемле, мәгарифле булуы белән дан тоткан. Безнең дин галимнәре язган китаплар бөтендөнья мөселман өммәте мирасының бер өлеше. Халкыбыз күп еллар дәвамында милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрнең уникаль тәҗрибәсен туплаган. Без бу тәҗрибәне киләсе буыннарга да тапшырырга бурычлы.

Дин - бар буын кешеләре өчен дә Аллаһы Тәгаләнең нәсыйхәте, нигъмәте. Барчабызга да Раббыбызның иксез-чиксез рәхмәтләренә ирешергә, гомерләребезне хәерле итеп үткәрергә насыйп итсен! Ил-көннәребезгә тынычлык-иминлек, бәрәкәт бирсен иде!

**Халкыбызның данлы тарихын, рухи мирасын саклап, буыннардан-буыннарга җиткерүче мөкатдәс Болгар шәһәрендә быел да олы җыен узды. Болгар җыенында Татарстан мөселманнары белән бергә Казанда өч көн дәвам иткән "Милли тормыш һәм дин" VI Бөтенроссия татар дин әһелләре форумы делегатлары, Россия мөселманнары Диния нәзарәтләре рәисләре, Төркия, Әзербәйҗан, Бангладеш, Иран, Ирак, Пакьстан, Алжир, Малайзия, Польша, Үзбәкстан, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Иордания, Бәхрәйн - барлыгы 20 илдән килгән кунаклар, "Россия - ислам дөньясы" Стратегик күзаллау төркеме эшчәнлеге һәм ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең I Халыкара Казан яшь эшкуарлар форумы кысаларында Казанда узучы җәйге лагерьга чакырылган яшьләр дә катнашты.**

### "Без гыйлемле бабаларыбыз юлын дәвам итәргә тиеш"

"Милли тормыш һәм дин" форумына Россиянең 63 төбәгеннән 900 дән артык делегат чакырулы иде. Делегатлар 4 секциягә бүленеп эшләде. Алар "Ислам һәм татар дөньясы: үсешнең концептуаль нигезләре" концепциясен тормышка ашыру программасы, тарларда дини йолалар һәм бүгенге җәмгыятьтәге тормыш, мәктәп һәм дин, татар халкында дин һәм милли үзаң мәсьәләләренә багышланган темаларга фикер алышты.

"Форум быел 6 нчы тапкыр уздырыла. Без монда дини мәсьәләләрне генә түгел, башка сорауларны да карыйбыз. Милләтнең киләчәге, телебез, яшьләребез хакында фикер алышабыз. Ул мәсьәләләрне чишү өчен форумда катнашучылар башкаларның фикерләренә хөрмәт белән карарга, бер-берләрен тыңлый белергә, бердәм булырга тиеш, - дип башлады пленар утырыштагы чыгышын Татарстан Президенты вазыйфаларын башкаручы Рөстәм Миңнеханов. - Бер- береңне тыңлый белү - бик кирәкле сыйфат. Бүген ислам дөньясы кырыс сынаулар уза, шуларның берсе халыкара терроризм янаулары. Ислам динен пычратырга теләүчеләр бар. Бу проблемалар безгә генә түгел, бөтен дөньяга кагыла. Кыенлыкларны бердәм булсак кына җиңеп чыга алачакбыз. Исламга карата булган мөнәсәбәтне җитәкчеләр дә күрә, - диде Татарстан лидеры, һәм РФ Президенты Владимир Путин кушуы буенча, әлеге юнәлештә эш алып баручы стратегик төркем төзелүен, анда 28 ил вәкиле катнашуын һәм аның белән Рөстәм Миңнеханов үзе җитәкчелек итүен искәртте. "Без бердәм булсак, фикерләребез дөрес булса, Президент та аларны кабул итәр. Шушы форумда сөйләшкән фикерләрне "Россия - ислам дөньясы" стратегик төркеменең эшчәнлегендә файдалану зарур", - диде Рөстәм Миңнеханов. Соңыннан делегатларның кайберләре Рөстәм Миңнеханов кулыннан ТР Президентының Рәхмәт хатларын алды.

"Җыен безне берләштерә торган бер күркәм чара. Җыенда үзара аралашып, фикер алышабыз, тәкъдимнәр ясыйбыз һәм тәҗрибә уртаклашабыз. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дигән: "Мөэмин мөэмин өчен бина кебек, бер-берсен ныгытып тора". Без дә





# МӨСЕЛМАННАРЫН ТОРАЧАК






бер-беребезне эшләребез һәм сүзләребез белән нygытып торабыз. Менә шушы ныклыкны алга таба саклар өчен биредә сөйләгән-әйткән сүзләрне гамәлләр белән дә нygытсак, тормышка ашырсак, иншә Аллаһ, тагын да файда булыр, - дип, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан мөселманнарны берләштерү, гыйлемнәрен үстерү юнәлешендә башкарылган эшләргә тукталды. - Беренчедән, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан расланган "Гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында нигезләмә" дөнья күрде. Әлеге нигезләмәне ТР МДНнең Голәмалар шурасы ел дәвамында казыйлар белән берлектә әзерләде. Дини йолаларны башкару тәртибен белмәү аркасында кайбер мәхәлләләрдә хәтта фетнә чыгу куркынычы яный. Нигезләмә Татарстанда гына түгел, Россиянең башка төбәкләрендә яшәүче мөселманнарга да дини эшләрне алып баруда кулланма була алачак. Нигезләмәдә вәгазь сөйләү тәртипләре дә күрсәтелгән һәм аларны татарча сөйләү кирәклеге хакында ачык әйтелгән. Бай рухи мирасы белән танылган татар мөселманнары татар телле булган. Татар теле динне, милләтне саклаучы нygытма, - дип, Камил хәзрәт Сәмигуллин икенче юнәлешкә дә тукталды. - Хәнәфи мәзһәбе мәктәбе татарларга милләт булып калырга һәм иманнарын югалтмаска ярдәм иткән. Бүген дә безне ул ясалма агымнардан, төрле фетнәләрдән, замана чирләреннән саклый. Бу хакта "Ислам һәм татар дөньясы: үсешнең концептуаль нигезләре" концепциясендә ачык язылган...

Тарихи чыганакларда Болгар галимнәр, белгечләр иле буларак язылган Беренче Болгар университеты "Дар әл Гылем" (Гыйлем йорты) 1080 елда ачылган. Аны галим Ягкуб Ибн Ногмани ачкан. Әлеге университет халыкара статуска ия булган. Бүгенге көндә Болгарны мөселман рухи үзәге буларак торгызу буенча яңа адымнар ясала. Болгарда рухи, дини-фәнни һәм гыйлем бирүне берләштергән комплекс - Болгар ислам академиясен оештыру эшләре алып барыла. Аллаһы боерса, озакламый биредә алты айлык Коръән өйрәнү курслары ачылачак. Болгар ислам академиясе комплексының төп оешмаларыннан берсе - Бөтенроссия голәмалар берлеге булачак. Белгәнебезчә, хәзерге вакытта төрле нәзарәтләр каршында голәмалар шуралары эшләп килә. Кызганыч, кайчак билгеле бер дини мәсьәлә буенча төрле эчтәлектәге фәтвалар кабул ителә. Бу исә фикерләр каршылыгына китерә.

**(Ахыры 10 нче биттә.)**

## Сәнгатебезнең асыл көзгесе



**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте февраль аенда "Минем гаиләмнең шәмаиле" акциясен игълан иткән иде. Әлеге акция кысаларында беренче мәртәбә татар шәмаилләренә багышланган Россиякүләм сәнгать конкурсы уздырылды. Конкурс "Традицион татар шәмаиле", "Һәвәскәр каллиграфия", "Балалар иҗаты", "Гаилә ядкаре" номинацияләрендә барды.**

Конкурска Россиянең төрле төбәкләреннән, шулай ук Казахстаннан, Австралиядән барлыгы 300 эш кабул ителде. Дин әһелләре һәм сәнгать белгечләреннән торган жюри шорт-биткә 120 эшне сайлап алды.

21 майда - Идел Болгарында исламны рәсми кабул иткән көндә Кол Шәриф мәчетендәге Ислам мәдәнияте музеенда һәм Татар шәмаиле галереясында "Минем гаиләмнең шәмаиле" беренче Россиякүләм сәнгать конкурсы кысаларында күргәзмә ачылды. Ислам мәдәнияте музеенда Татарстан районнарыннан, Казан, Түбән Новгород өлкәсеннән, Чувашиядән җыелган 50 гә якын борынгы шәмаил урын алды. Беренче мәртәбә бирегә куелган татар шәмаилләре Казан һәм республика музейларында саклаучы шәмаилләрне сан һәм сыйфат ягыннан узып китә. Берничә шәмаил XIX гасырга карый. Күбесен XX гасырда, совет заманында татар осталары ясаган.



Ә 1 июнь көнне Казанның Гаилә мәчетендә "Минем гаиләмнең шәмаиле" беренче Россиякүләм сәнгать конкурсында катнашучы балаларның күргәзмәсе оештырылды. Конкурска 50дән артык бала үзләренең эшләрен тәкъдим итте. Алар арасында Чаллы, Лениногорск, Казан, Актаныш, Питрәч, Азнакайдан һәм башка районнардан, Пензадан катнашучылар бар. Шулай ук Австралиядән бер төркем татар балалары конкурска шәмаилләр ясап җибәргәннәр.

Жюри сайлап алган конкурс номинантларына интернеттан тавыш бирү исә конкурсның Кол Шәриф мәчетендә үткәрелүче йомгаклау тантанасында туктатылды.

**(Ахыры 10 нче биттә.)**

## Сәнгате - безнең асыл көзгесе

**(Ахыры. Башы 9 нчы биттә.)**

Бәйрәмдә мөфтинең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батыр, "Казан Кремле" музей-тыюлыгы җитәкчесе Зилә Вәлиева, Иранның Казандагы консулы Рәсүл Шаян, каллиграф Нәҗип ага Нәккаш, Кол Шәриф мәчете имам-хатыйбы Илфар хәзрәт Хәсәнов, Ислам мәдәнияте музее директоры Нурия Гәрәева, төрле төбәкләрдән килгән кунаклар, шәмаил ясау осталары һәм башкалар катнашты. Бәйрәмне яшь мөнәҗәт башкаручылар Сәйдә Мөхәммәтҗанова, Энҗе Әхмәтҗанова, Базарбай Бикчәнтәев, олуг шәхесләребез Миңгол Галиев, Геннадий Макаровларның чыгышлары бизәде.

Иң күп тавышны "Шәһри Биләр" шәмаиле - авторы Фирдәвес Гыйрфанов җыйды (Чаллы). Икенче урынга "Фатиха" сүрәсе - авторы Чулпан Шәрифуллина (Чаллы), өченче урынга - "Әл-Ихлас" сүрәсе авторы - Әлфия Исхакова (Казан) лаек булды. Моннан тыш борынгы шәмаилләрне саклауда активлык күрсәтүче Казанның Рафыйк мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Сафиуллинга, иң өлкән яшьтәге шәмаил ясау остасы Габделхак Бикмуратовка (Питрәч районының Шәле авылы имамы) конкурсның махсус бүләкләре тапшырылды.

"Тарихи шамилләрне бер-берсеннән аерып карау мөмкин түгел, барысы да зурлауга лаек", - дип, жюри "Гаиләм ядкаре" номинациясендә аерым урыннар билгеләмәде. Аларны саклап, кадерләп тоткан һәм күргәзмәләргә китергән гаиләләргә конкурс дипломнары һәм истәлек бүләкләре тапшырылды.

"Мөселман каллиграфиясенең барлык төрләре" дип аталган юнәлештә ("Һәвәскәр каллиграфия" номинациясе) төрле жанрда иҗат ителгән "Һәр җан үзе тудырган нәрсәләрнең тоткыны" (авторы - Җәмил Әхмәтгалиев, Уфа); "Бисмилләһи Рахман Рахим" (авторы - Айдар Кунаев, Екатеринбург); "Шәһри Болгар" (авторы - Раиф Мәрданов); "Илаһи мәхәббәт" (авторы - Айзат Минһаҗев); "Аллаһ гүзәл: Ул гүзәллекне ярата" (авторы - Алсу Насыйбуллова); "Төшке аш" догасы (авторы - Ришат Сәлахетдинов) шәмаилләре финалга чыкты.

Тамырларыбызны барларга, үзебезнең догалы, сәнгатьле халык икәнлекне искә төшерергә, безгә генә хас булган бу сәнгать төрен кире кайтарып, зур дәрәҗәгә күтәрергә, дигән нияттән оештырылган бу конкурс максатына ирешер, шәт. Әнә никадәр оста-һәвәскәрләрне, бала-чаганы һәм өлкәннәрне кулга кылкаләм алырга мәҗбүр итте, иҗатка этәрде ул. Бәйге җиңүчесе Фирдәвес ага Гыйрфанов сүзләре белән әйтсәк, сәнгатебезнең асыл көзгесе булган шәмаилнең мөмкинлекләре гаять зур, аны ясаган саен тирәнрәк чума барасың.

# БОЛГАР ҖИРЕ ИЛЕБЕЗ МӨСЕЛМАННАРЫН БЕРЛӘШТЕРЕП ТОРАЧАК



**(Ахыры. Башы 8-9 нчы битләрдә.)**

Шуңа күрә дә Россия күләмендә дини сорауларны тикшерүче, өйрәнүче һәм карарлар кабул итүче Бөтенроссия голәмалар берлеген булдыру мөһим. Берлеккә дини югары белемле, гарәп телен камил белүче, Россиядә тыелган оешмалар белән бәйләнмәгән, Россия гражданины булган тирән белемле мөселман дин белгечләре кирәчәк. Берлек дини һәм сәяси сорауларны чишү, тиз арада хәл итү өчен фәтвалар чыгаручы төп дини-фәнни орган булыр, иншә Аллаһ".

Мөфти хәзрәт үзенең чыгышында нәзарәт зур игътибар биреп килгән дини мәгариф мәсьәләләренә дә тукталды: "Соңгы елларда Татарстан мөфтияте бердәм уку-укыту стандартларын булдыру, дини мәгарифне үстерү максатыннан күп сандагы эшләр башкарды. Шушы эшләрнең нәтиҗәсе буларак программалар әзерләнде һәм яңа уку елыннан башлап, Татарстан дини уку йортларына яңа уку-укыту стандартлары кертелә башлый. Шушы программаларны укыту өчен хәзерге вакытта әсбаплар әзерләнә.

Татарстан мөфтиятенең "Хузур" нәшрият йорты тарафыннан беренче сентябрьгә алтмыш өч дәреслек бастыра. Татарстан дин әһелләре, галимнәре, мөгаллимнәре тарафыннан әзерләнгән уку-укыту программаларын төрле төбәкләрдәге мәдрәсәләргә дә тәкъдим итәргә мөмкин. Дини гыйлем бирүдә фикерләребез, юнәлешебез, юлларыбыз бер булса, бердәмлек тә ныгыр, иншә Аллаһ.

Шул ук вакытта онытмыйк - гыйлемне бала чактан үзләштерү җиңел. Бу дини белемгә дә кагыла. Шуңа күрә дә балаларны дингә, әхлакка өйрәтүдә соңга калмыйк. Безгә йөзләгән, меңләгән дин галимнәре, докторлары үсеп чыккан халык буларга язсын. "Галим булсаң - галәм синеке", "Галим үләр - сүзе калыр, йөргән җирендә эзе калыр", - дигән бабаларыбыз. Мондый сүзләрне бары тик белемле кеше генә әйтә һәм аңлата ала. Димәк, без гыйлемле бабаларыбыз юлын дәвам итүче буын булырга тиеш.

Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен өммәтебез, республикабыз, илебез өчен бергәләп күркәм гамәлләр кылыйк, динебезгә хезмәт итик. Ватаныбызны хөрмәтлик һәм аның кадерен белик".

## Болгар җыены

Болгар җыенын рәсми ачу тантанасы алдыннан Изге Коръән берөзлексез укыла башлаган Ак мәчеттә Россия мөселманнарының социаль доктринасына кул куелды. Әлеге документны Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте рәисе шәйхелислам Тәлгать Таҗетдин, Россия Мөфтиләр шурасы рәисе һәм Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе мөфти Равил Гайнетдин, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, Төньяк Кавказ мөселманнарының координацион үзәге рәисе, мөфти Исмәгыйль хаҗи Бердиев имзалады. Доктрина ярдәмендә Россиядә яшәүче теләсә кайсы дин һәм милләт вәкиленә исламның төп принциплары һәм бәхәс уята торган трактовкалары аңлаешлы булачак. Документ җәмгыятьтәге әхлак һәм сәламәт яшәү рәвеше, гаилә һәм балалар, ватанпәрвәрлек, экстремистлыкка каршы көрәш мәсьәләләрен, шулай ук, дәүләт һәм дәүләт хезмәтенә, Россия законнарына, башка дин вәкилләренә мөнәсәбәт һ.б сорауларны колачлый.

Болгар җыенының тантаналы өлеше Истәлек билгесе бинасы янында Татарстанның Яшел Үзән районы имам-мөхтәсибе Габделхәмит хәзрәт Зиннәтуллинның Коръән укуы белән башланып китте. Бәйрәмгә җыелган халыкны Татарстан Президенты вазыйфасын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов сәламләде: "ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кергән Болгар җирендә мөселманнарга ата-бабаларыбызның рухына дога кылу һәм көнүзәк мәсьәләләрне уртага салып сөйләшү өчен елдан-ел уңайлы мөмкинлекләр тудырыла. Быелгы җыенда Россиядә ислам дине үсешенә кагылышлы мөһим карарлар кабул ителде. Киләчәктә дә Болгар җире илебез мөселманнарын берләштереп торсын".

Татарстанның Дәүләт киңәшчесе һәм республиканың "Яңарыш" тарихи һәм мәдәни истәлекләрне торгызу фонды җитәкчесе Минтимер Шәймиев үзенең чыгышында Болгар шәһәрчеген торгызу һәм төзекләндерүгә үз өлешен керткән барча кешеләргә рәхмәт сүзләрен әйтеп, Болгарның ислам динен өйрәнү үзәге буларак танылачагына ышанычын белдерде.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да үзенең чыгышында бүгенге көндә Болгар ислам академиясен оештыру буенча җитди эш алып барылуы, илдә дини сорауларны тикшерүче, өйрәнүче һәм карарлар чыгаручы Бөтенроссия галәмалар берлеген оештырырга җыенулары хакында сөйләде.

Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте рәисе шәйхелислам Тәлгать хәзрәт Таҗетдин исә Болгарга бүләк алып килгән, ул Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең соңгы 110 елда Уфа каласында сакланган сакал бөртекләрен музейга тапшырды. Төньяк Кавказ мөселманнары Координация Советы рәисе Исмаил хаҗи Бердыев сөйләгәнчә, Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм үзе исән чакта чәч бөртекләрен таратып, аларның бәрәкәт китерәчәген әйтеп калдырган. "Бу ядкяр Татарстанга, Россиягә бәрәкәт китерсен. Россия мөселманнары берләшсен, ә дәүләт җитәкчеләре моңа этәргеч бирсен", - диде Исмаил хаҗи. Россия Мөфтиләр шурасы рәисе, Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин республиканың һәм татарлар яшәгән төбәкләрнең милли һәм рухи күтәрелеш кичерүендә Татарстан күрсәткән ярдәмнең әһәмиятен ассызыклап, дин әһелләренең хезмәтен югары бәяләве өчен Татарстан җитәкчелегенә рәхмәтләрен җиткерде.

Сәгать 11дә Болгар шәһәрлегенең Кече манарасы янында Тәлгать Таҗетдин тәүбә чарасы үткәрде. Аннан соң мөкатдәс Болгар җирләрен зиярәт кылырга килгән барча мөселманнар, җамигъ мәчет хәрабәләренә тезләнеп, җәмәгать белән өйлә намазын укыды, бабаларыбызның рухларына дога кылды.

Бәйрәм чарасы исә күренекле сәнгатькәрләребез башкаруындагы мөнәҗәтләр, борынгы халык көйләреннән торган концерт программасы белән дәвам итте. Җыенда катнашучылар Истәлек билгесе бинасында ачылган Коръән музее белән таныша алды.

Дини китап нәшриятларының күргәзмә-ярминкәсеннән, Болгар һөнәрчелеге үзәгеннән дә кеше өзелеп тормады, мөселманча милли кием-салым, хәләл ризык, оста һөнәрчеләр чатырларында сәүдә гөрләде.

# ИФТАР АШЛАРЫНА КИЛЕГЕЗ

| МӨХТӘСИБӘТ | МӘЧЕТЛӘР | УЗДЫРЫЛУ ВАКЫТЫ | ИСКӘРМӘЛӘР |
|---|---|---|---|
| АЛЕКСЕЕВСК | жамигъ мәчет (Пушкин ур.)<br>Урта Тигәнәле | ай дәвамында | |
| АЗНАКАЙ | Ак мәчет (Мәрҗани ур.41) | ай дәвамында | |
| | Зәңгәр мәчет (Тукай ур.2а) | берничә тапкыр | |
| | Кәкре Елга мәчете | | |
| АРЧА | жамигъ мәчет<br>(Галактионов ур., 38а) | берничә тапкыр | |
| | Көнбатыш мәчете<br>(Сибирский тракт. 16) | берничә тапкыр | |
| | Станция мәчете (Ватан урамы) | берничә тапкыр | |
| | Кенәр<br>Шушмабаш<br>Мөрәле | берничә тапкыр | |
| АКТАНЫШ | жамигъ мәчет (Советская ур.,22а) | көнаралаш | |
| ӘГЕРҖЕ | жамигъ мәчет | ай дәвамында | |
| | барлык мәхәлләләрдә | берничә тапкыр | |
| АПАС | Миргасыйм мәчете (М.Җәлил ур.,38) | бер тапкыр | |
| | 2 нче мәчет (Красноармейская ур.,69а) | бер тапкыр | |
| | 3 нче мәчет (Кооператив ур.,15) | бер тапкыр | |
| | Олы Бакырчы | бер тапкыр | җирле |
| | Таугилде | бер тапкыр | хакимият |
| | Урта Балтай | бер тапкыр | ярдәме белән |
| | Каратун мәчетләре | бер тапкыр | уздырыла |
| ӘЛКИ | Актай мәчете<br>авыл мәчетләре | берничә<br>тапкыр | |
| БАЛТАЧ | жамигъ мәчет | берничә тапкыр | авылларда |
| | Раиф мәчете | берничә тапкыр | хуҗалыкларда уздырыла |
| БАЛЫК БИСТӘСЕ | жамигъ мәчет | 2 тапкыр | |
| | Биектау | | |
| | Тәб.Чаллы | | |
| | Яңавыл | | |
| | Күгәрчен | | |
| | Береговой | | |
| | Иске Арыш | | |
| | Тулыш | | |
| БАУЛЫ | Гали мәчете (Р.Ваһапов ур.35а) | ай дәвамында | |
| | Өмет мәчете (Татарстан ур.,1а) | ай дәвамында | |
| | Тат. Томбарлы,<br>Кызылъяр | берничә тапкыр | |
| БУА | Хаҗилар мәчете (Западная бистәсе) | ай дәвамында | |
| | Госман мәчете<br>(Р.Люксембург ур., 150) | берничә тапкыр | |
| | Мәлик мәчете | берничә тапкыр | |
| | Мәдрәсә (К.Либкнехт ур.,79) | берничә тапкыр | |
| | Суксу авылы мәчете | берничә тапкыр | |
| БИЕКТАУ | жамигъ мәчет (Полк ур..10) | ай дәвамында | |
| | Администрация каршындагы мәчет | ай дәвамында | |
| | Гафиятулла мәчете | ай дәвамында | |
| | барлык авылларда | берничә тапкыр | |
| БӨГЕЛМӘ | жамигъ мәчет<br>(Краснослободская ур. 68) | ай дәвамында | |
| | Ирһам мәчете (Воровский ур.,1) | ай дәвамында | |
| | Ислам нуры (Чайковский ур.,10а) | берничә тапкыр | |
| | Бәдер мәчете<br>авылларда | көнаралаш<br>берәр тапкыр | |
| ЗӘЙ | жамигъ мәчет (Т.Ялчыгол ур.,16) | ай дәвамында | |
| | Түбән мәхәллә мәчете | берничә тапкыр | |
| | Тынычлык мәчете | берничә тапкыр | |
| | Аксар мәчете | | |
| | Куш-Елга мәчете | | |
| | Бура-Киртә | | |
| | Югары Шепкә | | |
| КАЗАН | Мәрҗани мәчете (К.Насыйри ур., 17) | ай дәвамында | |
| | Тынычлык мәчете (Мирный бистәсе) | ай дәвамында | |
| | Ярдәм мәчете (Серов ур., 4а) | ай дәвамында | 800-1000 кешелек |
| | Гаилә мәчете (Ж.Фәйзи ур., 2) | ай дәвамында | 400-500 кешелек |
| | Казан нуры (Чистай ур.) | ай дәвамында | 300-400 кешелек |
| | Ислам динен кабул итүгә<br>1000 ел исемендәге мәдрәсә<br>(М.Гафури ур., 67) | ай дәвамында | |
| | Хузайфа мәчете (Ю.Фучик ур., 53) | ай дәвамында | |
| | Ризван мәчете (Х.Мәүлетов ур., 48а) | ай дәвамында | |
| | Мәдинә мәчете (Курчатов ур.4а) | ай дәвамында | |
| | Кабан арты мәчете (Һ.Такташ ур.) | ай дәвамында | ДУМ РТ, республика хөкүмәте, Казан хакимияте ярдәме белән уздырыла |
| КАЙБЫЧ | жамигъ мәчет (Үзәк урам) | берничә тапкыр | |
| | Борындык<br>Һәр мәхәллә | 3 июль<br>берәр тапкыр | |
| КУКМАРА | Хәйрия мәчете (Нур Баян ур.) | ай дәвамында | 200 кешелек |
| | мәдрәсә (Мичурин ур.,6) | берничә тапкыр | |
| | авыл мәчетләрендә, хуҗалыкларда | | |
| ЛАЕШ | жамигъ мәчет (Юбилей ур., 68) | ай дәвамында | |
| | Сокуры | ай дәвамында | |
| | Кече Елга | ай дәвамында | |
| | Столбище | 19 июнь | |
| ЛЕНИНОГОРСК | жамигъ мәчет | берничә тапкыр | |
| | барлык мәчетләрдә | берничә тапкыр | |
| МАМАДЫШ | Әхмәд Ясәви мәчете | берничә тапкыр | |
| | районның 55 мәчетендә дә | берничә тапкыр | |
| МӨСЛИМ | жамигъ мәчет | ай дәвамында | |
| | һәр авыл мәчетендә | берничә тапкыр | |
| МИНЗӘЛӘ | жамигъ мәчет | берничә тапкыр | |
| | авыл мәчетләрендә | берничә тапкыр | |
| ЧАЛЛЫ | | 1 июль | мөфти хәзрәт һәм шәһәр мэры катнашында |
| | Ак мәчет | 19 июнь | |
| | Туфан мәчете | 20 июнь | |
| | Нур-Ихлас | ай дәвамында | |
| | Кәүсәр | берничә тапкыр | |
| | Әбүзәр | 10 көн | |
| | Җамигъ мәчет | ай дәвамында | |
| | Рамадан | 18 июнь | |
| | Сөембикә | 3 тапкыр | Хәләл үзәк белән бергә |
| | Ихлас | ай дәвамында | |
| | Билал | берничә тапкыр | |
| | ГЭС | | |
| | Чишмә | | |
| | Круглое поле | | |
| САБА | Шәмәрдән мәчете | ай дәвамында | |
| | жамигъ мәчет | берничә тапкыр | |
| | авыл мәчетләрендә | берничә тапкыр | |
| САРМАН | жамигъ мәчет | ай дәвамында | |
| | Тәүфыйк мәчете | ай дәвамында | |
| | Җәлил бистәсе<br>Шәрләрәмә | ай дәвамында | |
| | барлык мәчетләрдә | берничә тапкыр | |
| НУРЛАТ | 41 мәчетнең<br>барысында да | ай дәвамында | Хакимият тарафыннан район ифтары уздырыла |
| ЯҢА ЧИШМӘ | Зирекле | ай дәвамында | |
| | Яңа Чишмә | | |
| | Шахмай мәчетләре | | |
| ПИТРӘЧ | Кокушкино | берничә тапкыр | |
| | Шәле | берничә тапкыр | |
| | жамигъ мәчет | берничә тапкыр | |
| | Званка | ай дәвамында | |
| | Көек | | |
| | Район ифтары | 5 июль | 300 кешелек |
| СПАС | жамигъ мәчет | берничә тапкыр | |
| | Чәчәкле | | |
| | Иске Рәҗәп | | |
| | Ямбакты | | |
| | Әзмәр мәчете | | |
| ТУКАЙ | Яңа Бүләк | берничә тапкыр | |
| | Бәтке | берничә тапкыр | |
| | Биклән | берничә тапкыр | |
| | Теләнче Тамак | берничә тапкыр | |
| | Иштирәк | берничә тапкыр | |
| ТЕЛӘЧЕ | жамигъ мәчет | берничә тапкыр | |
| | Олы Мәтәскә | берничә тапкыр | |
| | Лесной бистәсе | берничә тапкыр | |
| ТӘТЕШ | жамигъ мәчет (Свердлов ур., 103а) | берничә тапкыр | |
| | Кадрия мәчете<br>(Тәтешнең 200 еллыгы ис.ур.) | берничә тапкыр | |
| ЧҮПРӘЛЕ | жамигъ мәчет (Иске Чүпрәле) | берничә тапкыр | район үзәгендә район ифтары |
| | 15 ләп мәхәлләдә | берничә тапкыр | уздырыла |
| ЮТАЗЫ | жамигъ мәчете | 10р көн | |
| | “Фәнис” мәдрәсәсе | 10 көн | |
| | Кече Урыссу авылы<br>2 нче мәхәллә мәчете | 10 көн<br>10 көн | |
| ЯШЕЛ ҮЗӘН | 1 нче мәхәллә<br>жамигъ мәчет | ай дәвамында<br>берничә тапкыр | |
| | Тынычлык мәчете | берничә тапкыр | |

## III Республика ифтарына волонтерларны чакырабыз

**26 июньдә "Казан-Арена" стадионында 5 мең кеше катнашында III Республика ифтары уздырыла. Ифтар ашына чакырылучылар арасында күп балалы һәм аз керемле гаиләләр, ятим балалар, шулай ук сәламәтлекләре начар булган кешеләр дә бар. Аларның һәммәсе дә ярдәмгә мохтаҗ. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте актив яшьләрне Республика ифтарына волонтер булырга чакыра.**

Диния нәзарәтенең яшьләр эшләре бүлеге җитәкчесе Айгөл Биктимерова яшьләрнең массакүләм чараларны оештыруда актив катнашулары бик мөһим дип саный. "Һәр елны мөселман яшьләре зур чараларны - Республика ифтарын һәм "Болгар җыены"н уздыруда үзләреннән зур өлеш кертеп килә. Быел да яшьләребез активлык күрсәтерләр һәм без III Республика ифтарын югары дәрәҗәдә уздырырбыз, дип өметләнәм. Бүгенге көнгә волонтерлар исемлеген төзү белән мәшгульбез. Үзебезнең зур командабызга инициативалы, битараф булмаган яшьләрне чакырабыз. Аларның һәркайсына махсус бүләкләр әзерләдек", - ди Айгөл.



# АНА ХАКЫ

**Бөтен галәмне юктан бар кылучы Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгаләгә һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребез түреннән чыккан салават-шәрифәләребез булса иде.**

Һ**ӘР**кемнең тормышында иң изге кеше ул - әни. Чын күңелдән безне яратучы бердәнбер кеше дә - әни. Ялгышларыбызны, хаталарыбызны һәрдаим гафу итүче, кичерә белүче иң олы йөрәкле кеше дә - әни. Ничә яшебезгә җитсәк тә, безне сабый бала кебек кайгыртып, безнең өчен ут йотып яшәүче дә - әни. Дөньяга аваз салуга ук ул безне җил-яңгырдан саклап үстерә, олы тормыш юлына әзерли, акыллы киңәшләре белән ярдәм итеп тора. Әти-әниләр олыгаеп, безнең ярдәмгә мохтаҗ булганда, аларга йомшак сүзләр белән генә дәшсәк иде. Сәламәтлегебез, исәнлегебез булганда әти-әниләребезне карарга, алар янына кайтып йөрергә, хәлләрен белешеп торырга иренмәсәк иде. Ислам дине дә әни кешеләрне олуг дәрәҗәгә күтәрә, хәдисләрендә аңа хөрмәт күрсәтүнең саваплы булуын каткат дәлилли.

Алар алдында тагын нинди бурычларыбыз бар? Әлбәттә, без алар белән яхшы мөгаләмәдә булырга, аларга игътибарлы, эшләрендә ярдәмчел, киң күңелле, һәрбер әмерләренә итагатьле булырга тиешле. Ата-анага игелекле булу һәрбер мөселманга фарыздыр, аларга каршы бару зур гөнаһлардан санала. Аллаһы Тәгалә Үзе Коръәндә әмер рәвешендә әйтә: "Аллаһка гыйбадәт кылыгыз һәм Аңа ширек китермәгез Һәм ата-анагызга игелекле булыгыз". Ягъни яхшы мөнәсәбәттә булыгыз вә итагать итегез!("Ниса" сүрәсе, 36).

Икенче бер аятьтә Аллаһы Тәгалә әйтә: "Аллаһ хөкем итте вә әмер бирде, фәкать Аллаһка гына гыйбадәт кыйлырга һәм ата-анага изгелек итәргә. Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә картлыкка ирешсәләр, син аларга "уф" та димәгел, вә каһәрләмә, кәефләрен җибәрмә, бәлки аларга һәрвакыт йомшак вә мөлаем сүзләр сөйләгел!"("Исра" сүрәсе, 23).

"Уф"дигән сүз татарчага "туйдырдың"дип тәрҗемә ителә. Аллаһы Тәгалә, ата-анагызга хәтта "уф" та дип әйтмәгез, дип боера, ә без әти-әнигә генә түгел, Аллаһның Үзенә дә "уф, Алла" дип әйтергә яратабыз. Әти-әниләребез безне тәрбияләр өчен бөтен көчен вә тырышлыгын сала, барча мәхәббәтен безгә юнәлтә, ә без нәрсә белән җавап бирәбез? Кайберәүләр хәтта, өйләрендә урын калмагач, аларны картлар йортына илтеп тапшыра, мөгаен, мондый бәндәләрнең йөрәкләре урынында таштыр. Ата-анасын рәнҗеткән бәндәләргә нинди газап әзерләнгәнен әллә алар белми микән? Расүлебез галәйһиссәлам әйтте: "Аллаһы Тәгалә өч төрле кешегә җәннәтне хәрам кылды: исерткеч эчүчегә, ата-анасын рәнҗетүчегә, гаиләсендә бозыклык урнаштыручыга".

Без гомеребез буе ата-аналарыбызга игелек кылсак та, аларның хакларын түләп бетерә алмыйбыз. Алар безнең җәннәтебез, яисә җәһәннәмебез,



ягъни әгәр без аларга игелек кылсак, аларны хөрмәтләсәк, алар бездән разый булып, без Аллаһның җәннәтләренә керәбез, әгәр без каты бәгырьле булсак, ата-аналарыбызны рәнҗетсәк, аларга ихтирамсыз булсак, алар бездән разый булмас һәм хур булып җәһәннәмгә ташланырбыз, Аллаһ сакласын.

Сабый вакытыбызда алар безне тәрбиялиләр, төннәрен йокысыз үткәрәләр, бер дә авырсынмыйлар, без үсеп ныгыгач, көннәрдән бер көнне Аллаһ аларның егәрен ала, инде хәзер ата-аналарыбызны без тәрбияләргә, алар безне ничек тәрбияләгән булса, без дә шулай ук җавап кайтарырга тиеш булабыз.

Бер кешенең атасы булган, картлык сәбәпле ашаган вакытта ризыкларын чәчкәли икән. Бу килен кешегә ошамый, ул иренә мөрәҗәгать итеп әйтә: "Әтиең ашаганда куллары калтырый, ризыкларын чәчә, әйдә, без аны икенче бүлмәгә күчерик булмаса", - ди. Алар шулай эшлиләр дә, әмма шайтан гел вәсвәсәләп тора, килен тагы иренә мөрәҗәгать итә: "Әтиең безгә авыр йөк, аның артыннан карап йөреп тәмам арыдым, җыештырып та туйдым, әйдә, без аны куып чыгарыйк"- ди. Шулай итеп, мескен әти кешене урамга куалар, улы әтисен жәлләп, туңарсың дип, җылы юрган бирә, ә бу вакыйганы кечкенә бала күреп тора: "Әти, - ди ул, - юрганның яртысын кисеп алып кал". "Нишләп?"- дип сорый әтисе, аптырап. "Сине чыгарып җибәргәндә үзеңә дә кирәк булыр".

Аллаһы Тәгалә безгә Коръәндә әйтә: "Вә аларга шәфкать итеп, рәхим канатларыңны җәйгел! Вә әйт: "Ий Раббым, алар мине кечкенә чагымда мәрхәмәт белән үстергәннәре кебек, Син дә аларга дөньяда һәм ахирәттә шәфкать кыйл!"Күңелләрегездә нинди ниятләр вә теләкләр барын Аллаһ белә, әгәр күңелләрегез яхшы булса, Аллаһ, әлбәттә, тәүбә итеп төзәлгән кешеләрне гафу итәдер" ("Исра", 24-25).

Әти-әниләрегез өчен дога кылыгыз! Чын бәхеткә ирешәсегез килсә, аларның ризалыгын алырга тырышыгыз! Мин сезгә тормыштан алынган бер кыйсса сөйләргә телим.

"Улым, савыт-сабаларны өстәлдән генә алып куйчы, башым бик каты авырта", - диде әнисе һәм, бераз гына булса да аркасын терәп алу өчен, эчке бүлмәгә таба атлады. "Алырсың әле, вакытым юк", - диде улы ачулы тавыш белән һәм, бүлмәсенә кереп, ишеген шапылдатып ябып куйды...

Үзгәрде Ришат, үзгәрде... Кечкенә вакытында бик мөлаем малай иде. Газиз ана тормыш иптәшен җирләп, гаилә хуҗасын югалтканнан соң: "Терәгем син булырсың инде, улым", - дип өметләрен аңа баглады. Тормышта авырлыклар күп булса да, сабыр булды, сынмады. Ир балам бар, картаймыш көнемдә ул ташламас, дип ныгып килүче баласыннан юаныч эзләде...

Ләкин нәрсә булды аның кечкенә улына? Сәбәп ата тәрбиясе эләкмәүдәме, әллә газиз баланың йөрәген явыз бүреләр урладымы? Ныгып җитүе генә булды, улы юлдан яза башлады. Сау-сәламәт ир-егет беркайда эшләми, салгалап та кайткалый. "Әнием", - дигән сүзләрне дә күптән ишеткәне юк ананың. "Тездә чакта сөйдерә, тездән төшкәч көйдерә", - дигәннәр бит борынгылар, белми әйтмәгәннәр, күрәсең. Көйдерде Ришат әнкәсенең йөрәген, тәмам картайды ана. Теләсә нәрсә кычкыра, төнлә кайтып исерек баштан тавыш куптара. Газиз татар анасы үзенә хас булган сабырлык белән улына һич нәрсә әйтми, чәен куя, урын-җирен хәзерли, киемнәрен юа...

Соңгы арада бигрәк таушалды ана, яшь тә үзенекен алады. Кайнар ашы, бүген генә пешергән ризыклары белән улын сыйлап, бераз ятып торыйм, дип бүлмәсенә атлады. Улы да, гадәтенчә, ашап-эчкәннән соң бүлмәсенә кереп ятагына ауды. Боргаланып күпме вакыт яткандыр, кинәт, өй эчендә артык тыныч, караңгы булып китте. Егетнең күңеле шомланды, йөрәген ниндидер курку алды. Ул урыныннан торып, бүлмәсеннән алгы якка чыкты... Сәер, табын өстендә торган савыт-саба урыныннан селкенмәгән. Ашаганнан калган ипи валчыклары да сөртелмәгән. Тиз генә әнисе яткан бүлмәгә керде. Бераз ятып кына торыйм дигән ана артык тыныч күренә. Ришат бер мизгелгә сулышын өзеп, әнисенең сулавын ишетергә теләде, ләкин һичбер тавыш-тын килмәде. Үзе дә сизмәстән, ул: "Әнием, әнием", - дип кычкырып җибәрде. Ләкин ана селкенмәде. Егет ятак янына тезләнде, аркасына яткан әнисе кырына башын салды, кулын үзенең кулларына алды, ләкин ана кулында җылы тапмады... Кечкенә вакытында бу куллар никадәр йомшак була иде. Кичләрен төрле уйларга чумып, йоклап китә алмый ятканда әнисенең җылы куллары аны бик тиз йокыга талдырды. Бервакыт, күрше малайлары белән туп тибеп уйнаганда егылып, аягын авырттырып кайткач та, шушы йомшак кулларның авырткан җирне бер сыпыруы, мөлаем тавышы белән: "Улым", - дип дәшүе, малайның бар авыртуларын баскан иде. Ләкин шифалы кулларга нәрсә булган, алар ник салкын? "Әнием, әнием", - дип кабатласа да, әнисе ни өчен: "Улым", - дип әйтми? Әнисенең җансыз гәүдәсен кочкан Ришат: "Әнием, эндәш миңа, эндәш, мин синең улың бит, кечкенә улың, эндәш миңа, әнием... Китмә миннән, мин сине күпме рәнҗеттем, кичер мине, әнием!"- дип өзгәләнде...

"Әнием" сүзен күптән әйткәне юк иде Ришатның. Әнисен бер генә мизгелгә булса да кайтарып, җылы кулларыннан тотасы, бер генә тапкыр булса да "улым" дигән сүзен ишетәсе, "Әнием, кичер мине, рәнҗемә", - дип ялварасы килде. Моның өчен ул үз җанын да фида кылырга әзер иде...

Шулвакыт, егетнең кулларыннан кемдер тотып: "Улым, нәрсә булды, улым, саташасың, ахры", - диде. Сискәнеп күзләрен ачкан егет каршысында басып торган әнисен күрде. Әйе, исән-сау газиз әнкәсе басып тора. "Ришат, балакаем, йокы аралаш бик кычкырдың, шуңа борчылып кердем",- дип дәвам итте әнисе. Ришат үз күзләренә үзе ышанмыйча, әнисенең җылы кулларыннан алды, моңсу күзләренә карап, арык гәүдәсен күкрәгенә кочты...

Әнкәй... Шушы олуг сүзне без никадәр аз әйтәбез. Алар янәшәбездә исән-сау булганда кадерләрен белмибез. Дөнья эшләре, үз балаларыбыз мәшәкатьләренә башаяк чумып, дөнья һәм ахирәт бәхетенә сәбәп булган әнкәй фатихасыннан үз-үзебезне мәхрүм итмәсәк иде. Аллаһы Тәгалә Коръәндә Ибраһим пәйгамбәрнең ата-анасына кылган догасын өйрәтте: "Ий Раббыбыз, үземне вә ата-анамны һәм барча мөэминнәрне ярлыка, Кыямәт көнендә хур итмә!"("Ибраһим" сүрәсе, 41).

**Тимергали хәзрәт ЮЛДАШЕВ,**
**ТМДНнең дәгъвәт бүлеге белгече**

# Хиҗапмы, әллә калфакмы?

*Хезмәттәшем Илнур белән языშып утырабыз. Тормыш, яшәү мәгънәсе турында... Шундый глобаль мәсьәләләр арасында минем яулыгым да бар, әлбәттә. Ни өчен әле мин япь-яшь башыма яулык бөркәнгәнмен? 60 яшьләргә җиткәч кисәм ни булган, янәсе. Минем өчен гап-гади һәм бик тә аңлаешлы нәрсә булса да, күпләр төшенеп бетми шул әле яулык ябуның серләренә.*

*Хәзерге вакытта хиҗап киюнең татарлар өчен хас булмаганлыгы турында күп сөйлиләр. Бу мәсьәләдә чәчләре агарып бетеп, әле һаман да ак яулыгын чөеп бәйләмәгән татар әбиләре дә шактый "мәгълүматлы". Имеш, болай яулык ябу ул гарәпләрдә генә, ә татар хатын-кызлары башкача киенә торган булганнар: алар чигелгән калфактан йөргәннәр, башларындагы чәчләре өлешчә күренеп тә торган. Ә бу чынлыкка туры киләме соң?*

*Тарихи мәгълүматлар белән танышырга иренмәгән кешегә моның киресен дәлилләүче бик күп кызыклы язмалар, хезмәтләр бар. Аларны укыганда без нәкъ менә ерак әбиләребезнең һәрвакыт хиҗаптан, алай гына да түгел, хиҗапның муенны каплап, алдан бәйләнә торган иң "кырыс" төрләрен киеп йөргәнлекләре турында белербез. Татарларда андый баш киемнәре бар җирләрдә дә таралыш алган булган: Казанда да, Әстерханда да, Касыймда да, себер татарларында да.*

*Ә арттан бәйләнә торган кыекча яулыклар басу-кырларда эшләүче крестьян хатын-кызларына гына хас булган. Вакытлар үтү белән шәһәр шартларында калфаклар, ягъни хатын-кызларның чәчен тулысынча каплап бетерми торган кечерәк баш киемнәре таралыш алган. XIX гасырның атаклы дин тәгълиматчысы, тарихчысы һәм мәгърифәтчесе Ш.Мәрҗани үзенең данлыклы " Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар " ( "Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр") хезмәтендә бу уңайдан болай диеп язып калдырган: " Хәзер, кызганыч, хатын-кызлар калфак киеп йөри башлады, алар аны кияүгә чыккач та киеп йөри". Әлеге мәгълүматларга караганда, кайберәүләр татар хатын-кызлары өчен мөмкин булган берд әнбер баш киеме итеп карый торган ул калфакларны киеп йөрү чынбарлыкта исә халкыбызның күп гасырлык тарихына чагыштырмача күптән түгел генә килеп кергән булып чыга. Ә тарихны белмәгәннең киләчәге юк, диләр бит. Тарихны өйрәнү ул - бик тә файдалы, өйрәнегез. Шул ук вакытта Ш.Мәрҗани "яулыклары белән башларын тулысынча каплап йөрүче", " күкрәкләрендә махсус күкрәкчәләре булган һәм озын җиңле күлмәкләрдән йөргән" хатын-кызларны үрнәк итеп күрсәтә. Чөнки андый кием мөселман хатын-кызларына күбрәк туры килә, ди. Менә шушы мисалдан чыгып кына фикер йөртсәк тә, хиҗап татар хатын-кызлары өчен ят кием дип раслау хакыйкатькә туры килми.*



*Тагын бер нәрсәне искәртәсем килә. Халкыбызның зирәклеге - аның чын мөселманча сабыр итә белүендә, шул исәптән, аның дин күрсәтмәләрен төгәл үтәп бетермәүчеләргә булган сабыр мөнәсәбәтендә. Татар хатын-кызларының бүгенгә кадәр килеп җиткән киемнәре дә шул сабырлык нәтиҗәсе, минемчә. Башкача була да алмый инде, чөнки дини кануннарны үтәүдә кеше иректе булырга тиеш.*

*Мин үзем татар милли бизәкләре чигелгән күлмәкләргә, һәм яулык өстеннән матур гына кадап куелган чигүле калфаклар киеп йөрүгә бер дә начар карамыйм. Киресенчә, болай киенү бик тә матур һәм зәвыклы диеп саныйм. Инде соңгы вакытларда мөселман кибетләрендә татар милли киемнәре дә урын ала башлады. Сезнең киемегез һәм хәрәкәт итү чарагыз иң яхшы ( күркәм) булсын, шул вакытта сез кешеләр арасында йөздәге миңгә тиң булырсыз, җәмгыятьне бизәрсез, диелгән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер күркәм хәдисендә. Минемчә, хиҗап ул матурлыкны каплап торучы икенче бер матурлык. Һәм моның мәгънәсе дә бик тирән булырга тиеш, уңайлы, матур кием булу белән бергә хатын-кызга Аллаһ кушканны җиренә җиткереп башкарырга ярдәм итүендә дә.*

**Сөмбел ШӘРИФУЛЛИНА**

# Тишек оекбашлар һәм хушугъның югалуы

*Хөрмәтле хәзрәтебезнең җомга вәгазе һәрвакыттагыча эчтәлекле, сабак алырлык һәм гыйбрәтле булды. "Намазга баскан кайбер дин кардәшләребезнең күбрәк үзләренең тышкы кыяфәтләре белән мавыгулары аларның эчке дөньясына, дини-рухани халәтенә тискәре йогынты ясый. Ә кайберәүләрнең, үз алдына гына карап, җаны-тәне белән бирелеп, уй-хисләрен бары тик Аллаһы Тәгаләгә юнәлткән хәлдә гыйбадәтен ихлас күңелдән башкарыр вакытта янәшәсендәге берәрсенең тишек оекбаштан булуы, я булмаса ыштанын күтәреп кияргә өйрәнмәгән бер мөселман кардәшнең сәҗдәгә киткән чакта арт санының ярымшәрә калуы аның игътибарын үзенә җәлеп итәргә, шуның аркасында кылган намазы Аллаһка ирешми калырга мөмкин", - дип тә искәртте ул.*



*Хәзрәт вәгазь сөйләгән арада юеш аякларын йомшак келәмгә ышкып сөртә-сөртә алдыма яланаяклы ике иптәш килеп басты. Хәзрәт әйткәнчә, теләмәсәм дә игътибарым аларга юнәлде. Күңелемне әлеге күренешкә риза булмаган уйлар биләп алды. Тәнем чымырдап китте, күзәнәкләрем аша кайнарлык йөгереп үтте. Чөнки нәкъ менә шушы иптәшләр кебек гыйбадәт урынына яланаяк керүчеләр аркасында яман чиргә тап булып, байтак вакыт азапланырга туры килгән иде. Кемнеңдер авыру аягыннан келәмдә калган бактерияләр сәҗдәгә киткән вакытта минем маңгаема кунаклаган. Башта маңгаемның тиресе җиңелчә генә кычыта башлады. Тора-бара һаман саен ныграк кычыта барып, бөтен башыма таралды.Табиб киңәше белән бер даруның әле тюбиклысын , әле бармак башы хәтле генә флаконлысын 600-700 әр сумга сатып алып, дүрт айдан артык дәваланганнан соң, Аллаһының рәхмәте белән, ниһаять, бу афәт бетү ягына авышты.*

*Инде хәзрәтебез үзенең вәгазендә искә алып үткән әлеге дә баягы тишек оешбашлар, ярымшәрә калган артлар хакында фикер йөрткәндә, таякның юан башы нәкъ шушы җитешсезлекләрнең хуҗаларына төшәргә; хәзрәтнең нәсыйхәтен алар үз адресларына алып, нәтиҗә ясарга тиеш инде югыйсә. Чөнки нәкъ менә шулар Аллаһы Тәгаләнең изге йортын чын күңелдән ихтирам итеп, ямаулы булса да чиста-пөхтә, намаз укыр өчен яраклы киемнән булсалар, безнең күңелләр дә вәсвәсәгә бирелмәс, аларга игътибар итеп, намазыбызга зыян китермәс идек. Яңа оекбашларның бәяләре дә хәзер бик кыйбат түгел ләбаса.*

**Рәис САФИН,**
**Казан**

# Сугыш җиле безнең гаиләгә дә кагылган

*1941 елның 22 июне... Авылларда шау-гөр килеп милли бәйрәмебез – Сабантуен үткәрәләр. Менә радиодан куркыныч хәбәр ишетелә: "Сугыш башланды!" Бик күп ир-атлар илебезне сакларга сугышка китә. Безнең гаиләдән дә яу кырына берничә ир-ат чыгып киткән. Бабайның олы абыйсы, әбинең әтисе, дәү бабайның кече энесе... Бабайның абыйсы 1947 елда исән-сау өенә кире әйләнеп кайткан. Әбинең әтисе Гали бабай сугыша-сугыша Венгриягә хәтле барып җиткәч, 1945 елда һәлак булган.*

*Ә карт бабамның кече энесе Ибраһимов Габделхак Исхак улы сугышка 1941 елда алына, ул да Венгриягә хәтле барып җитә. Бик кыю, куркусыз булганга аны дус-ишләре хөрмәт итәләр, бик яраталар. Яуда сыналган хәрбине Япония сугышына да җибәргәннәр. Ул генерал Власов армиясендә сугышкан һәм фашистларга пленга төшкән, хәтта аннан да качу әмәлен тапкан. Туган иленә, халкына тугрылыклы солдат сугыш беткәнче фронтта булган. Сугыш беткәч, җиңү салютлары яңгырагач, өенә кайтып килешли аны кулга алалар. Чөнки власовчылар халык дошманы – илне сатучы мөһерен йөрткәннәр. Колыма сазлыгыннан әзерләнгән тоткыннар шулпасын байтак эчеп, замана сәясәте белән кыйналып, бөкре юлаучы хәлендә, ниһаять, туган йорты бусагасын атлап кергән ул.*

*Ә сугыш вакытында карт әбиемә каты сугышлар барган җирләрдән 28 баланы китерәләр. Шулай итеп, үзенең 6 баласы өстенә тагын бер взвод бала-чага өстәлә. Ул чор балалары бик зур кыенлыклар кичергәннәр, әмма иманлы һәм кешелекле булып үсеп җиткәннәр. Вакыты белән табыннарында бер сынык ипи дә булмаган, шундый чакта да кеше әйберенә кул сузмаганнар.*

**Гөлназ ЗАРИПОВА,**
**Алабуга шәһәренең 10 нчы мәктәбе**
**6 сыйныф укучысы**

# БОЛГАР ТӨРЕКЛӘРЕНЕҢ ДИН ВӘ МӘЗҺӘБЛӘРЕ

**Болгар төрек кавеменнән булганлыктан, аларның иске төрекләр иялгән диннәрдән һәм мәзһәбләрдән берәрсенә иярган булулары табигый. Ислам барлыкка килгәннән соң, кайсы еллардадыр Болгар мәмләкәтенә һәм Болгар кавеме арасына ислам дине керде һәм яхшы гына таралды. Чөнки боларның рухи халәтләренә ислам дине яраклы һәм туры килә торган иде.**

Башлап ислам динен кабул итүләренә тышкы сәбәпләрне бәян итүчеләр дә бар. Ләкин шул төрле сәбәпләр арасыннан җиңелен һәм дөресен табу - беркадәр авыр. Аны белүгә зур ихтыяҗ да юк.

Һәрхәлдә, Болгар төрекләре үзләре белән сәүдә мөнәсәбәтләрендә һәм солых хәлендә яшәүче иранлылар аркылы Гарәбстан җирендә барлыкка килгән ислам хәбәрен бик иртә белгәннәр булса кирәк. Габделмалик бине Мәрдан заманында ислам кабул иткән хәзәр төрекләре арадашлыгы белән дә боларга ислам дине кергән булуы ихтимал.

Болгар төрекләренең ислам динендә булуы рәсми рәвештә һиҗри белән 310 (милади белән 922) елның12 мөхәррәме саналырга тиешле.

Бу көнгә кадәр дә Болгарда ислам дине ачыктан-ачык һәм җиренә җиткереп тотылуы, хәтта мәчеттә дә җомга намазы укылу һәм хөтбәдә Болгар ханы телгә алынып дога кылынуы Ибне Фазланның: «Без килгәнгә кадәр хөтбә вакытында падишаһ өчен мөнбәрдә : «Аллаһүммә әслихәл-мәликә Бәлтуар-мәликә Болгар», - дип дога кылына торган булган», - дигән сүзләреннән мәгълүм. Мәчетләр һәм мөнбәрләр төзелү, җомга намазы укылу һәм җомга хөтбәсендә падишаһка дога кылыну - бу мәмләкәттә күп заманнар элек ислам дине тамыр җәйгән булуга дәлил.

Ибне әл-Әсирнең һиҗри белән 433 ел вакыйгаларыннан итеп: «Болгар кавеме төрек һәм сәкълаблар арасында туган. Аларның шәһәрләре - төрекләрнең иң ерак шәһәре. Алпар кәферләр иде, Карибләреннән, ягъни якыннарыннан ислам динен кабул иттеләр. Алар - Әбү Хәнифә (Аллаһ аннан разый булса иде) мәзһәбендә», - дигән сүзендәге «кариб»не беркадәр еллардан гына гыйбарәт дип белү яраклы түгел, бәлки ул сүздән булган максат - болгарларны Сәмәрканд, Амудәрья һәм Сырдәрья далаларындагы төрекләр итеп күрсәтүдер.

Мәсгуди Болгар хакында: «Болгар шәһәре Мантыш диңгезе ярына урнашкан. Мин аларның җирнең җиденче кисәгендә урнашканнарын күрәм. Алар - төрекләрнең бер төре. Харәзем һәм алар арасында Хорасан һәм Харәзем җирләреннән һәм башка җирләрдән кәрваннар йөри. Ә инде әгәр тегендә, ягъни башка тигезлекләрдә төрекләрдән кәрваннар йөрсә - алар болгарның милке санала. Безнең хәзерге вакытыбыз - 332 ел. Мөселман диненә әл-Моктәдир көннәрендә 310 елда керделәр. Теге күрүче аны күрде һәм ул хаҗга барып, тынычлык шәһәрендә, ягъни Багдадта догалар укыды. Аның белән әл-Моктәдир байрак күтәрде һәм аларны мәчеткә алып барды», - ди.

Якут Хәмәви: «Болгар хөкемдары һәм аның кешеләре әл-Моктәдир биллаһ көннәрендә ислам динен кабул итте. һәм Багдадка илче җибәрде, әл-Моктәдирне белделәр һәм аннан намаз укырга һәм шәригать кануннарына өйрәтүен сорадылар. Ләкин алар исламга бу сәбәптән генә кермәде», - ди.

Хәмәвинең бу сүзеннән болгарларның элек ислам кабул итеп, шуннан соң хәлифәгә илче күндереп, дин өйрәтүчеләр җибәрүен сораганлыклары аңлашыладыр.

Һәрхәлдә, болгар төрекләренең ислам кабул итүләренең сәбәбе ачык беленми. Төрле сәбәпләр булуы ихтимал. Болгар сәүдәгәрләренең Багдадта ислам диненнән хәбәрдар булып, кызыксынып кайткан булулары, Багдадта төрекләрнең дәрәҗә яулаулары һәм шуның тәэсире булуы кебек эшләр - һәммәсе болгар төрекләренең ислам кабул итүләренә сәбәп булырга мөмкин.

Ибне Фазланның: «Сәкълабларның хөкемдары Алмас бине Сүлки Бәлтуарның мөэмин-мөселманнарның әмире Әл-Моктәдир биллаһка хаты иреште. Анда ул ислам шәригатен кабул итеп, диннең кануннарын өйрәнеп, аңа тугрылыклы булулары турында ант итүләре хакында һәм үзләре өчен мәчетләр һәм мөнбәрләр төзүне сорап яза. Мәмләкәтнең бөтен шәһәрләрендә төрле хөкемдарларның һөҗүмнәреннән саклану өчен крепостьлар төзүне сорый...» - дигән сүзеннән ислам диненең инде кабул ителгән, аның мәмләкәт эченә инде кертелгән булуы, хәзер төп максат кальга төзү икәнлеге, дин турында бары тик ияртеп кенә искә алынуы аңлашыладыр.

Һәрхәлдә, болгар төрекләрендә ислам дине ныклы рәвештә урнашты, хәлифәлек үзегеннән һәм ислам бишегеннән ерак булуларына карамастан, Аллаһы Тәгаләнең өстенлеге һәм мәрхәмәте белән дини гадәтләр үтәлеп торды. Бу эш - болгар төрекләренең ислам кабул итүләре дөньяви бер киңлек өчен генә булмыйча, бәлки халыкны тирән аңлаулары аркасында динне күңелдән тануларына дәлил. Юкса җилдән килгән мәхәббәт, төш һәм кәрамәт юнәлешендәге эшләр сәбәбеннән генә хасил булган ихласның шул эшнең киресе булган икенче төрле җил һәм икенче төрле кәрамәт сәбәбеннән югалуы һәм, һәрхәлдә, ныклы булмавы, гомумиләшмәве мәгълүм.

Өч йөз елдан артык вакыт үтте. Болгар төрекләре әхлаклары соңгы дәрәҗәдә бозык, мөгамәләләре җәбер һәм золым булган рус түрәләренең истибдадлары астында яшәп тә, үзләренең әхлакларын, гореф-гадәтләрен саклап килде, дингә ышанулары ныклы һәм какшамас булды. Руслар арасында торган хәлдә сакланган дин һәм дөньяга караш, Аллаһ теләсә, дәҗҗал көненә кадәр сакланыр.

**Ризаэддин Фәхретдин.**
**Болгар вә Казан төрекләре.**
**1912 нче ел.**
**(«Шура», №4)**

# КАЗАНДА ЗӘКЯТ ӨЛӘШҮ

**Рамазанның ахыргы җомгасы иде. Екатеринская урамындагы зур таш пулат алдына төркем-төркем фокара сыйныфы җыела башлады. Бу җыелган халык үзенең чуарлыгы, өстенә кигән киеменең төрлелеге, бер-берсенә кылган мөнәсәбәтләре вә кыланышлары белән теләсә кемне гаҗәпләндерерлек иде. Әнә тегендә торган әбинең өстендәге киеме бөтенләй сәләмәдән гыйбарәт булып, фәкать тәненә эленеп торыр дәрәҗәдә генә калган. Әнә тегендә кулына яшь ярымлык баласын тоткан бер хатынның өстендә иске күлмәк, башында тетелеп беткән шәл, аягында икесе ике төрле тишек ризинкә. Менә монда иптәше белән сөйләшә торган бер кыз кеше күзенә кызганычрак күренер өчен иң алама киемен киеп, чәчләрен туздырып, йөзенә фәкыйрьлек кыяфәте биреп тора. Кыскасы, зәкят алыр өчен җыелган бу халыкның мөмкин дәрәҗәдә начаррак, мөмкин дәрәҗәдә кызганычрак булырга тырышканлыгы әллә кайдан күренеп тора иде.**



Җыелганнар арасында кызганырга лаеклы зәгыйфьләр, кулсыз, аяксыз бәндәләр, сукыр, чалыш, саңгырау, телсез һәм яклаучысыз калган кешеләрне дә күрергә мөмкин иде.

Ни булса да, бу сәләмәләр дөньясы бер ел буена әзерләнеп, байның зәкят биргән көнен көтеп алган, шул көн җиткәч тә, иртән иртүк торып, кешедән алдарак тору һәм башкаларга караганда зәкяттән күбрәк өлеш эләктерү өчен капка төбенә килеп сөялгән. Кем белә, ихтимал алардан кайберсе зәкят өләшүче хезмәткярләр белән әллә кайчаннан бирле хәбәрләшеп куйганнардыр. Алар да үзләренә күрә сәясәт корган булганнардыр.

Бу халык төрле киемдә, төрле калдык-постык сәләмәдән булган кебек, араларындагы сөйләшүләре, кыланышлары да төрлечә иде. Һәркем ни булса да кычкыра, нәрсәгәдер иптәшенә ачулана, ни өчендер җыелган халыктан яисә зәкят өләшүчедән берәрсен сүгә, нәрсә хакындадыр үзара талашалар, шуңа күрә дә һичбер төшенүе мөмкин булмаган тавыш купкан иде.

Шул буталчык тавыш эчендә, бу сәләмә дөньясыннан һәркем зәкят өләшә торган капкага тыгылган, һәркайсы бүтәннән алдарак керергә тырыша, мәхрүм буласы килми, этә-төртә булса да эчкә керә һәм шуңа күрә тыгызлык, буталу булып тавышның куәтләнүе өстенә сугышның да чыгуына сәбәп була иде.

Этешкән вакытта кайсы кычкыра, кайсы җылый, кайсы көлә иде.

- Тукта! Анда кая тыгыласың? Өлгерерсең әле! Әллә монда син генәме?

- Синең ни эшең, тыгылсани? Син дә бит тыгыласың!

- Тыгылса? Алданрак кил идең!

- Аллаһ, Аллаһ, үтерәсез! Аягыма бастыңыз!

- Җибәреңез, җибәр! Баланы таптыйсыз!

- Әни, әни! Син кайда?

Тегендә, капка төбендә эш тагын да яманрак булып, зәкяттән өлеш алырга кергән сәләмәләр дөньясының кулы өскә күтәрелгән, һәркем алдан үзенә бирүен таләп кыла.

- Абый, миңа!

- Миңа да!

- Миңа бирмәдең, әнә тегеңә ике рәт бирдең!

- Нәрсә бу? Бары шул гынамы? Шундый байлык беләнме? Мин моны кер юган өчен дә алмыйм!

- Балам күп, үзем фәкыйрь, ирем юк, зинһар, бәбкәм, тагы бир!

- Туктагыз, тукта! Барыңыз да үрелмәңез! Син кая тыгыласың, өлгерерсең! Барыңызга да булыр...

- Сиңа бит бирдем! Тагы ни кирәк? Башкалар да бар бит!

- Аз булса китер бире. Күп бирүчеләрдән алырсың!

- Бар, бар, кит инде! Башкаларга юл бир. Кит дим! Җилкәңә аласың киләме?

- Сугып кара!

Зәкят өләшүчеләр белән алучылар арасында шундый сүзләр тәкрарланганнан тәкрарлана иде.

Өлеш тигәннәрнең үзләреннән дә бер төсле сүз чыкмыйча, кайсы байны мактый, кайсы яманлый, кайсы өләшүчеләрне сүгә иде.

- Бай имеш! Тукта байлыгың бетәр әле!

- Байлык бер айлык ул! Зәкят өләшәм дип, ятимнәрне алдый. Синең ике тиенеңә мин төкермим дә.

**(Ахыры 15 нче биттә.)**

# УРАЗА КИТАБЫ

*1. Әбү Һурайра тапшыруынча, Пәйгамбәр (аңа Аллаһының сәламе булсын): "Ураза ул - пәрдә[1], ураза тоткан кеше начар сүз сөйләмәсен һәм наданнарга охшамасын. Кем дә булса аның белән талашырга теләсә яки аны ачулана башласа, ул ике тапкыр: "Мин ураза тотам!" - дип әйтсен. Мин җаным Аның кулында булган Зат белән ант итәм, ураза тота торган кешенең авызыннан килгән ис Аллаһы тәгалә өчен мускусның хуш исеннән дә тәмлерәк һәм Ул: "Ул Минем өчен ризыктан, эчемлектән һәм үзенең дәртеннән баш тарта, бу уразаны ул Минем өчен тота һәм Мин аңа моның өчен әҗерен бирәчәкмен. Ә яхшы эшнең әҗере ун тапкыр артыграк булачак!" - дип әйтер", - дигән.*

*2. Сәһл риваять кылуынча, Пәйгамбәр (аңа Аллаһының сәламе булсын): "Чынлыкта, җәннәттә Әр-Рәййән[2] дигән капкалар бар һәм Кыямәт көнендә аңа бары тик ураза тоткан кешеләр генә керәчәк. "Ураза тоткан кешеләр кая?" - дип сорагач, алар уяначак һәм бу капкага алардан башка беркем дә кермәячәк. Алар җәннәткә кергәч, алар бикләнеләчәк һәм аларга бүтән беркем дә керә алмаячак", - дип сөйләгән.*

*3. Әбү Һурайра (Аллаһы аннан разый булсын) тапшырган: "Пәйгамбәребез болай дип сөйләде: "Аллаһы ризалыгы өчен үз малының ике тигез өлешен[3] корбан иткән кешене җәннәт ишекләреннән: "Йә Аллаһының колы, бу - изгелек", - дип чакырып алачаклар: намаз укыган кеше намаз капкаларыннан, изге сугышта катнашкан кеше җиһад капкаларыннан керергә, ураза тоткан кешене Әр-Рәййән капкасыннан керергә, ә садака биргән кешене садака ишекләреннән керергә чакырачаклар". Моны ишеткәч, Әбү Бәкер: "Әти-әнием, сиңа йолым булсын, йә Аллаһының илчесе, минем уйлавымча, бу капкалардан чакырылган кешеләргә беркайчан да, бернинди дә бәла булмаячак, ләкин андыйлар табылыр микән соң?" - дип сорады. Пәйгамбәр (аңа Аллаһының сәламе булсын): "Әйе, мин сине дә алар арасында булырсың дип өметләнәм!" - диде".*

*4. Әбү Һурайра (Аллаһы аннан разый булсын) тапшырган: "Пәйгамбәр (аңа Аллаһының сәламе булсын): "Рамазан җиткәч, җәннәт ишекләре ачыла!" - дигән.*

*Икенче хәдистә Пәйгамбәр (аңа Аллаһының салаваты вә сәламе булсын): "Рамазан ае җиткәч, күкнең капкалары ачыла, ә җәһәннәм капкалары бикләнелә һәм шайтаннар чылбыр белән бәйләп куела", - дигән.*

*5. Ибн Гомәр (Аллаһы аңардан разый булсын): "Айны күрсәгез[4], ураза тота башлагыз, ә аны тагын күргәч[5], уразагызны туктатсагыз да була, әгәр ай сездән яшеренгән булса, хисаплагыз", - дигән, ягъни ураза башланганда күргән яңа айдан башлап хисапларга кирәк.*

*6. Әбү Һурайра (Аллаһы аннан разый булсын) тапшырганча, Аллаһының илчесе: "Әгәр кеше ялганлаудан һәм алдау белән эш итүдән тыелмаса, Аллаһыга аның ашау-эчүдән баш тартуы кирәк түгел", - дигән.*

*7. Шул ук кеше риваять кылганча, Пәйгамбәр (аңа Аллаһының сәламе булсын): "Аллаһы Тәгалә: "Адәм баласы ни генә кылмасын, ул аның үзе өчен, ләкин бу уразага кагылмый, чөнки ураза ул Миңа тиешле әйбер һәм Мин аның өчен әҗерен бирәчәкмен!" - дип әйтте", - дигән. Пәйгамбәр (аңа Аллаһының сәламе булсын): "Ураза ул - пәрдә. Сездән кем дә булса ураза тота башласа, начар сүзләр сөйләмәсен һәм тавышын күтәрмәсен. Әгәр икенче кеше аны ачулана башласа яки аның белән талашырга теләсә, "Мин ураза тотам!" - дип әйтсен. Мөхәммәднең җаны Аның кулында булган Зат белән ант итәм! Ураза тотучының авызыннан килгән ис Аллаһы өчен мускус исеннән тәмлерәк. Ураза тоткан кеше ике тапкыр шатланачак. Аңа авыз ачу шатлык алып киләчәк, ә үзенең Раббысы белән очрашкач, ураза тотканына шатланачак"[6], - дип сөйләгән.*

*8. Габдуллаһ (Аллаһы аннан разый булсын) риваять кылган: "Бервакыт мин Пәйгамбәр белән булганда, ул (аңа Аллаһының сәламе булсын): "Никахның авырлыкларын күтәрә алырлык кеше өйләнсен, чөнки никах башка әйберләргә караганда карашны түбән төшерергә һәм гыйффәт сакларга булышачак. Моны күтәрә алмаслык кеше ураза тотарга тиеш һәм ураза аңа виджәне[7] алыштырачак", - диде".*

*9. Габдуллаһ бине Гомәр тапшыруынча, Пәйгамбәр (аңа Аллаһының сәламе булсын): "Бу айда[8] егерме тугыз көн, шуңа күрә аны[9] күрми торып ураза тота башламагыз, әгәр ул сездән яшерелгән булса - хисапны утызга җиткерегез!" - дигән.*

*10. Өмме Сәләмә тапшыруынча, бервакыт Пәйгамбәр бер ай буе хатыннары янына кермим дип ант иткән. Ә егерме тугыз көн үткәч, алар янына иртә белән (яки: "өйләдән соң") кергән. Аңа: "Син бит алар янына бер ай кермим дип ант иттең!" - дигәннәр. Ул (аңа Аллаһының сәламе булсын): "Ләкин ай бит егерме тугыз көннән дә тора ала!" - дип әйткән.*

*11. Әбү Бәкра тапшыруы буенча, Пәйгамбәр (аңа Аллаһының сәламе булсын): "Ике ай тулы түгел[10], төгәлрәге - бәйрәм айлары - рамазан һәм зөлхиҗҗә", - дигән.*

*12. Ибн Гомәр тапшыруы буенча, Пәйгамбәр (аңа Аллаһының сәламе булсын): "Чынлыкта, без надан халык, яза һәм хисаплый белмибез[11]. Ә ай андый да, мондый да була ала", - дигән. Айның егерме тугыз да, утыз да көннән тора алуын күз алдында тоткан.*

*13. Әбү Һурайра тапшыруынча, Пәйгамбәр (аңа Аллаһының сәламе булсын): "Сезнең берегез дә рамазанга бер, ике көн кала ураза тота башламасын. Бу нәрсә аның өчен гадәти хәл булса гына[12]. Бары тик шул очракта ул әлеге вакытта ураза тота башлый ала".*

*14. Әл-Бәра (Аллаһы аннан разый булсын) риваять кылган: "Мөхәммәднең сахабәләреннән кем дә булса ураза тотып, авыз ачар вакыт җитсә һәм ул кеше авызын ачмыйча йоклап китсә, ул кеше инде төнлә һәм иртән икенче көннең киченә хәтле бернәрсә дә ашамый иде. Бервакыт, Каис бине Сирмә исемле сахабә ураза тота һәм авыз ачар вакыт җиткәч, өенә кайта да хатыныннан: "Синдә нинди дә булса ашамлык бармы?" - дип сорый. Ул: "Юк, ләкин мин эзләп киләм", - дип әйтә. Әлеге кешегә килгәндә, ул көне буе эшләгән һәм шуңа күрә аны йокы баскан. Хатыны, кайткач: "Мин синең өчен бернәрсә дә тапмадым", - дигән. Икенче көннең уртасында әлеге ир кеше аңын югалтып егылган. Бу турыда Пәйгамбәргә (аңа Аллаһының сәламе булсын) сөйләгәннәр. Моннан соң аңа бу аять иңгән: "Сезгә ураза төнендә хатыннарыгызга якынаерга рөхсәт ителә[13] ..." Кешеләр моңа бик шатланган, ә аннары: "Сезнең алда кара җеп белән ак җеп аерыла башлаганчы ашагыз һәм эчегез!"[14] - дигән аять иңгән.*

*15. Һади бине Хәтим (Аллаһы аннан разый булсын) риваять кылган: "...Ак җеп белән кара җеп аерыла башлаганчы..." - дигән аять иңгәч, мин ак һәм кара бауны кулланырга уйлап, аларны мендәр астыма куйдым. Төнлә аларга карадым, ләкин бернәрсә дә аера алмадым. Иртә белән Пәйгамбәр янына килеп, бу турыда сөйләдем. Ул (аңа Аллаһының сәламе булсын): "Бу төннең караңгылыгы һәм көннең яктылыгы!"[15] - диде".*

*16. Зәйд бине Сабит (Аллаһы аннан разый булсын) риваять кылган: "Бервакыт без Пәйгамбәр белән рамазан аенда таң ату алдыннан ашадык, ә аннары ул намазга китте". Әнәс тапшырганча: "Мин: "Ә азан белән сәхәр[16] арасында күпме вакыт үтте?" - дип сорадым. Ул: "Илле аять укып чыгарга җитәрлек вакыт үтте", - дип җавап бирде".*

*17. Әнәс бине Мәлик тапшыруынча, Пәйгамбәр (аңа Аллаһының сәламе булсын): "Таң алдыннан ашагыз, чөнки ул - рәхмәт (теләк)", - дип әйткән.*

*18. Сәләмә бине әл-Әква риваяте буенча, бервакыт, Гашүрә көне җиткәч, Пәйгамбәр (аңа Аллаһының сәламе булсын) бер кешене халыкка бу сүзләрне җиткерергә җибәргән: "Инде ашаган кеше ризыктан тыелсын (яки: "...ураза тотсын..."), ә ашамаганнар бернәрсә дә ашамасын".*

*19. Гайшә һәм Өмме Сәләмә тапшырулары буенча, Пәйгамбәр, төнне хатыны белән үткәреп арусызланганнан соң, таңны каршы алганда, госел коенган һәм ураза тота башлаган.*

*20. Гайшә (Аллаһы аннан разый булсын) риваять кылган: "Пәйгамбәр ураза вакытында үзенең хатыннарын үбә һәм аларга кагыла иде, ләкин ул үзе белән сезнең һәрберегезгә караганда яхшырак идарә итә иде".*

*21. Әбү Һурайра тапшыруынча, Пәйгамбәр (аңа Аллаһының с әламе булсын): "Әгәр дә кеше ураза вакытында онытылып ашаса яки эчсә, ул кеше уразатотуын дәвам итсен, чөнки Аллаһы аны ашаткан да, эчерткән дә", - дип әйткән.*

**"Иманның татлылыгы. Сахих Бохари (хәдисләр)" китабыннан**

[1]. Ягъни җәһәннәм утыннан коткаручы.
[2]. «Яхшы итеп сугарылган, сусыл» дигәнне аңлата.
[3]. Яхшы эшләр өчен ниндидер иректә әйбер корбан иткән кешеләр турында сүз бара.
[4]. Рамазан башындагы яңа ай.
[5]. Ягъни икенче ай башында.
[6]. Мөселман кеше, ураза тоткан өчен Аллаһының әҗерен алгач, шатланачак.
[7]. «Виджә» — хайваннарны печү (кастрирование).
[8]. Ай календареның сигезенче ае — шәгъбан.
[9]. Рамазан башындагы яңа ай.
[10]. Ягъни зөлхиҗҗә рамазаннан кыскарак булса да, бу айны яхшы итеп уздырган кешегә Аллаһының әҗере кимеми.
[11]. Астрономик хисаплаулар ясый белмәү күз алдында тотыла.
[12]. Ягъни кеше рамазанда гына түгел, ә даими ураза тотса.
[13]. «Сыер» сүрәсе (2), 183 нче аять.
[14]. «Сыер» сүрәсе (2), 183 нче аять.
[15]. Коръәндә килгән ак һәм кара җеп — төн белән көннең аллегорик аңлатмасы. Ягъни төн белән таң яктылыгына алмашка көн килгәненә инанганчы ашагыз һәм эчегез.
[16]. «Азан» — намазга чакыру, «сәхәр» — рамазан аенда уразада таң алдыннан ашау.

# КАЗАНДА ЗӘКЯТ ӨЛӘШҮ

**(Ахыры. Башы 14 нче биттә.)**

- Әй, Ходаем! Ләгънәт төшсен шул өләшүчегә! Тиктомалга төртеп җибәрде, биш тиен бирә! Нигә мин биш тиенне алыйм?

- Рәхмәт төшсен! Аллаһ малларына бәрәкәт бирсен! Күлмәклек булды, шөкер Ходайга!

- Сөйләмә инде... абыстай! Байларның аз булса да, файдалары тия. Шундый байлар булмаса яулык кайдан алыр идең. Менә миңа яулык һәм чирек чәй эләкте.

- Сиңа күпме тиде? Мин ике рәт алдым.

- Чукынсын акчасы! Ходайның каһәре төшсен! Кеше талап тапкан акчалары белән күп тора алмаслар әле!

- Әй балам! Замана бозылды. Хаҗи терек заманда һәр кешегә күлмәклекләр, аның өстенә егермешәр тиен акча бирелә торган иде.

- Бу зәкятмени? Сукыр булсам да, мин зәкят белән зәкятне аера алам.

- Йә, аксак икәнне күреп тора, шунда да әзрәк кызганмый бит! Җитмәсә аксак шәйтан дип сүгә. Тукта! Җитәр бер заман, сине дә җилкәңнән төртеп чыгарырлар, син дә минем көнгә калырсың, Хода кушса!

Зәкят алганнар арасында шундый сүзләр сөйләнә. Һәркайсы кемне булса да мактап я сүгеп китәргә, икенче җирдә зәкят өләшкән җиргә барырга ашыга.

Бу сәләмәләр дөньясының гөжелдәве, аларның кемгә генә булса да начар тәэсир итмәслек түгел. Монда тормышның, татар тормышының һәм иң кызганыч һәм иң чиркандыргыч катлавы ачыла һәм бөтен галәмгә күренә. Менә бу Казан байларының зәкят өләшү рәвешләре. Болай өләшелгән зәкяттән ни фәкыйрьләр файдалана алалар, ни дә байлар рәхмәт ишетәләр, ни дә зәкят акчасы урынына китә. Зур шәһәрләремезнең һәркайсында хәйрия җәмгыятьләремез бар. Ул җәмгыятьләр халыкның үзе сайлаган кешеләре тарафыннан идарә кылынып, фәкыйрь, гаҗизләргә, юлда калучыларга, гыйлем эстәүчеләргә иганә итәләр вә мөмкин кадәр тәфтиш итеп мәзкүрләрнең лаеклылыгы исбатлангач кына бирәләр. Шулай булгач, зәкятләрне шул җәмгыятьләр аркылы өләштерү һәм уңайлы, һәм урыны, һәм файдалы булачагы ачыктыр. Ниндидер бер кирелек безнең байларымызны шул җәмгыятьләргә зәкят бирүдән тыеп тора.
"Кояш" 1913 ел, №200

**Язманы газета өчен Фатих ХӘБИБ әзерләде**

# УРАЗАГА НИЯТЛӘҮ һӘМ ИФТАР ДОГАСЫ

**Сәхәр ашаганнан соң уразага ниятләү догасы**

"Нәүәйтү ән әсуумә саумә шәһри рамәдаанә минәл-фәҗри иләл-мәгъриби хаалисан лилләһи Тәгалә. Әмиин".

"Аллаһ Тәгалә ризалыгы өчен ихласлык белән, таң вакытыннан башлап, кояш батканчыга кадәр, Рамазан ае уразасын тотарга ният кылдым.

**Ураза тотып авыз ачкач укыла торган дога**

"Аллаһүммә ләкә сумтү үә бикә әәмәнтү үә галәйкә тәүәккәлтү үә галәә ризкыйкә әфтартү фәгъфирлии йәә гаффаару мә каддәмтү үә мәә әххәртү".

"Әй Аллаһым, шушы уразамны Үзеңнең ризалыгың өчен тоттым, Сиңа гына иман китердем һәм фәкать бер Сиңа гына бөтен эшләремне тапшырдым. Син биргән ризык белән ифтар кылдым. Гөнаһларны гафу итүче Аллаһым, минем әүвәлге гөнаһларымны да, киләсе гөнаһларымны да ярлыка".

# "ЗӘКЯТ" ХӘЙРИЯ ФОНДЫ ИСЕГЕЗГӘ ТӨШЕРӘ

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең "Зәкят" хәйрия фонды Татарстанның барлык мәчетләрендә халыкны зәкят һәм сәдака түләүгә өндәүче плакатлар урнаштыра. Ул плакатларда зәкят түләүгә, аны таратуга кагылышлы төп сорауларны эченә алган мәгълүмат бирелгән. Фонд хезмәткәрләре мондый плакатлар зәкят түләүнең мөһимлеген халыкның исенә төшереп торыр, шулай ук зәкят акчаларын мәхәлләдә яшәүче мохтаҗларга тарату Татарстан Республикасы өммәте эшчәнлегендә һичшиксез уңай чагылыш табар, дип өметләнә.




# КАЗАН ӨЧЕН РАМАЗАН АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Милади 2015 ел | | Көн исеме | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Зәвәл | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы, ифтар | Ясту намазы, тәравих | Һиҗри 1436 ел | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | | | | |
| ИЮНЬ | 18 | Пәнҗ | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 11:44 | 12:00 | 17:33 | 20:31 | 22:01 | 1 | РАМАЗАН |
| | 19 | Җом | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 11:44 | 12:00 | 17:33 | 20:31 | 22:01 | 2 | |
| | 20 | Шим | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 11:44 | 12:00 | 17:33 | 20:32 | 22:02 | 3 | |
| | 21 | Якш | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 11:45 | 12:00 | 17:33 | 20:32 | 22:02 | 4 | |
| | 22 | Дүш | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 11:45 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 | 5 | |
| | 23 | Сиш | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 11:45 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 | 6 | |
| | 24 | Чәрш | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 11:45 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 | 7 | |
| | 25 | Пәнҗ | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 11:46 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 | 8 | |
| | 26 | Җом | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 11:46 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 | 9 | |
| | 27 | Шим | 01:00 | 01:30 | 03:00 | 11:46 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 | 10 | |
| | 28 | Якш | 01:00 | 01:30 | 03:00 | 11:46 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 | 11 | |
| | 29 | Дүш | 01:01 | 01:31 | 03:01 | 11:46 | 12:00 | 17:34 | 20:31 | 22:01 | 12 | |
| | 30 | Сиш | 01:02 | 01:32 | 03:02 | 11:47 | 12:00 | 17:34 | 20:31 | 22:01 | 13 | |
| ИЮЛЬ | 1 | Чәрш | 01:02 | 01:32 | 03:02 | 11:47 | 12:00 | 17:34 | 20:31 | 22:01 | 14 | |
| | 2 | Пәнҗ | 01:03 | 01:33 | 03:03 | 11:47 | 12:00 | 17:34 | 20:30 | 22:00 | 15 | |
| | 3 | Җом | 01:04 | 01:34 | 03:04 | 11:47 | 12:00 | 17:34 | 20:30 | 22:00 | 16 | |
| | 4 | Шим | 01:05 | 01:35 | 03:05 | 11:47 | 12:00 | 17:33 | 20:29 | 21:59 | 17 | |
| | 5 | Якш | 01:06 | 01:36 | 03:06 | 11:48 | 12:00 | 17:33 | 20:28 | 21:58 | 18 | |
| | 6 | Дүш | 01:07 | 01:37 | 03:07 | 11:48 | 12:00 | 17:33 | 20:28 | 21:58 | 19 | |
| | 7 | Сиш | 01:08 | 01:38 | 03:08 | 11:48 | 12:00 | 17:33 | 20:27 | 21:57 | 20 | |
| | 8 | Чәрш | 01:09 | 01:39 | 03:09 | 11:48 | 12:00 | 17:32 | 20:26 | 21:56 | 21 | |
| | 9 | Пәнҗ | 01:10 | 01:40 | 03:10 | 11:48 | 12:00 | 17:32 | 20:25 | 21:55 | 22 | |
| | 10 | Җом | 01:12 | 01:42 | 03:12 | 11:48 | 12:00 | 17:31 | 20:24 | 21:54 | 23 | |
| | 11 | Шим | 01:13 | 01:43 | 03:13 | 11:48 | 12:00 | 17:31 | 20:23 | 21:53 | 24 | |
| | 12 | Якш | 01:14 | 01:44 | 03:14 | 11:49 | 12:00 | 17:31 | 20:22 | 21:52 | 25 | |
| | 13 | Дүш | 01:16 | 01:46 | 03:16 | 11:49 | 12:00 | 17:30 | 20:21 | 21:51 | 26 | |
| | 14 | Сиш | 01:17 | 01:47 | 03:17 | 11:49 | 12:00 | 17:29 | 20:20 | 21:50 | 27 | |
| | 15 | Чәрш | 01:18 | 01:48 | 03:18 | 11:49 | 12:00 | 17:29 | 20:19 | 21:49 | 28 | |
| | 16 | Пәнҗ | 01:20 | 01:50 | 03:20 | 11:49 | 12:00 | 17:28 | 20:17 | 21:47 | 29 | |

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**


ДИН вә Мәгыйшәт

**Июнь саны, № 6 (239)**

**Мөхәррир:** Нәүбәһар КӘБИРОВА
**Дизайнер:** Гүзәл МИҢНУЛЛИНА
**Корректор:** Айгөл КРОХИНА
Газета логотибы **хәттат** Рамил НАСЫЙБУЛЛОВ тарафыннан эшләнде

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:** *420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27/*
**Электрон адрес:** *naubahar67@list.ru.*
**Телефон:** *+7 950 326 38 36*

**Редакция советы:**
*Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН**; "Хузур" нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН**; ТҖ МДНнең дәгъвәт бүлеге житәкчесе **Нияз САБИРОВ**; Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ**; Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы әгъзасы **Габдулла ӘДҺӘМОВ**.*

**Язылу индексы: 16046**
**Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин**

**Гамәлгә куючы:** *Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27).*
**Нәшир:** *"Хузур" нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 10в)*

*Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.*
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета **"Татмедиа" АҖ филиалы - "Идел-Пресс"** полиграфия-нәшрият комплексында басылды *(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)*.
**Тираж: 5 мең данә** Заказ **№ 9056**
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - **6 сум.**
График буенча бу санга **18 нче июнь** көнне **20.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде.
Кул куелды: **18.00 сәгатьтә.**